КАДЕРСЕЗ РИЗЫК

Бәянең түбән булуы мал санына тәэсир итәме?

> 2



ӘТНӘ АЗАНЫ

«Балалар күңеленә салынган иман орлыгы киләчәктә җимешләрен бирер»

> 7

ЛӘЙСӘН ГАТАУЛЛИНА:

«Сәхнә наданлыкны да, начарлыкны да – барын да күрсәтә»

> 8

ИКЕНЧЕ ВАТАНЫМ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 10

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 178–179 (29145–29146) | Сишәмбе | 5 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ӘШ һӘМ АШ

БАШКАЛАДА УЗГАН ТАТАРСТАН КӨНЕНДӘ СЫЕ ДА, МАКТАУ СҮЗЕ ДӘ КҮП БУЛДЫ

Вакыйга

Көчле, матур, онытылмаслык. «Россия» күргәзмә-форумында Татарстан көне булды. Мәскәү ВДНХсында биш урында узган чараларда республиканың икътисад, сәнәгать һәм башка өлкәләрдәге уңышлары белән уртаклаштылар, республиканың көчен һәм тормыш-көнкүрешен генә күрсәтеп калмыйча, милли гореф-гадәтләргә аерым игътибар бирделәр. Ә Балтачтан Зыятдиновлар гаиләсе исә иң зур туй уздырып кайтты.

«Төп байлык – кеше»

Татарстан көне уңаеннан узган чараларның рәсми өлеше башланганчы ук, ВДНХның мәдәни проектлар мәйданчыгына йөзләгән кеше җыелды. Араларында Татарстаннан килгән оештыручылар да, республикадан Дәүләт Думасына сайланган депутатлар да, бизнес вәкилләре дә, Шамил Тарпищев һәм Алинә Заһитова кебек спорт дөньясында танылган шәхесләр дә бар иде. Төп кунаклар килеп җиткәнче, алар бер-берсенең хәл-әхвәлен сораштылар, яңалыклар белән уртаклаштылар, Салаватның җырларын тыңлый торды.

Зур кунаклар арасында исә Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин, спорт министры Олег Матыцин, заманында Татарстанда эшләгән, хәзер исә Мордовия башлыгы Артем Здунов бар иде. Алар чара узган мәйданга Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән килде. Сәхнәгә күтәрелгәч, Рөстәм Миңнеханов Татарстанның илнең терәге саналган төп төбәкләрдән берсе булуын әйтте. «Без башкарганның, бездә булганның барысы да – Президент Владимир Путин алып барган сәясәт нәтиҗәсе, – диде ул һәм Россия Хөкүмәтенә дә рәхмәт әйтте. – Монда Хөкүмәттән дә коллегалар бар. Әйдәгез, ил җитәкчелегенә кул чабыйк! Мин озак сөйләмәячәкмен, чөнки бүген бездә 50дән артык чара булачак. Безнең белән бергә булганыгыз өчен рәхмәт. Татарстан, алга!»

> **Шамил ТАРПИЩЕВ,**
> **Россиянең Теннис федерациясе президенты:**
> – Нинди генә чаралар булмасын, Татарстан турында сөйләгәндә горурланып утырам. Республиканы илдә яшәү өчен иң яхшы урын дип тикмәгә генә әйтмиләр бит инде. Татарстанда барлык спорт төрләре үсә. Илнең башка бер генә төбәгендә дә мондый хәл юк. Республикада бу мәсьәләдә эшнең системалы рәвештә җайга салынуы сокландыра.
>
> **Алинә ЗАҺИТОВА,**
> **фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы:**
> – Татарстан – минем өчен кадерле, туган республика. Бүген аның өчен чын күңелдән горурланам. Күргәзмәдә Татарстан турында бик күп яңалык белдем. Спорт белән шөгыльләнгәч, республикага күбрәк спортчы күзлегеннән карый идем. Мондый чаралар исә Татарстан белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирә. Бигрәк тә яшьләр өчен.

Балтачтан Зыятдиновлар гаиләсе, Мәскәүдә туй уздырып, Татарстан Рәисенең хәер-фатихасын алды.

Вице-премьер Марат Хөснуллин да республикадагы хәлләрдән хәбәрдар. Татарстанның төп байлыгы дип ул кешеләрне атады һәм аларны кайгырткан өчен Рөстәм Миңнехановка һәм аның командасына рәхмәт әйтте. «Төбәкне чын мәгънәсендә тиз үсеш территориясе дип атарга мөмкин. Традиция буенча Татарстан барлык тармакларда да югары нәтиҗәләр күрсәтә», – диде ул. Марат Хөснуллин республикада быел 3 млн кв. метрдан артык торак файдалануга тапшырылганын, озакламый М12 «Көнчыгыш» трассасының 8 нче өлеше ачыласын искә төшерде. «Бу маршрут «Россия» дип атала, шуңа күрә бу – зур вакыйга», – диде ул. Ирек Фәйзуллин Татарстанны рекордлар территориясе дип атады. Олег Матыцин исә тормышының иң бәхетле елларын Татарстанда уздыруын әйтте. «Бүген игълан ителгән проектларга кагылышлы булуым белән горурланам», – диде ул.

Татарстан туе

Ачылу тантанасында республиканың уңышлары, алда көтелгән төп вакыйгалар турында сөйләделәр. Шулай да иң истә калган вакыйга туй булды. Балтачтан Самат Зыятдинов белән Сөмбел Ибраһимова Мәскәү сәхнәсендә гаилә корды. Алар белән бергә Россия башкаласына туганнары да килгән. Сүз уңаеннан, Саматның әти-әнисе 2020 елда Россия Президенты Указы белән «Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләнгән иде. Башта кияү белән килен артистлар белән туй йоласын күрсәтте, аннары аларның никахын рәсми рәвештә теркәделәр. Бүләге дә бар. Татарстан Рәисе яшьләргә Алтайга юллама тапшырды. «Бу – ясалма туй түгел. Бу – Балтач районыннан үрнәк гаилә. Яшь гаиләгә аяк өсте кул чабып, уңышлар, озын гомер һәм күп балалар теләп калабыз. Демография – төп мәсьәлә!» – диде Татарстан Рәисе.

Ахыры 3 нче биттә >

Табибка юл кыскара

Киләсе елда эшләүчеләргә хезмәт урынында мәҗбүри диспансеризация үткәрү гамәлгә кертелә. Россия вице-премьеры Татьяна Голикова әйтүенчә, моның өчен эш бирүчеләр медицина оешмалары белән килешүләр төзеячәк. «Эшләүчеләрнең табибларга юлын якынайту өчен, мәҗбүри медицина иминиятенә аерым тариф белән мәҗбүри диспансеризация уздыруны кертәчәкбез», – дип белдергән ул.

Голикова, 2024 елның Гаилә елы буларак игълан ителүен искәртеп, диспансеризация программасына хатын-кызлар һәм ир-атларның репродуктив сәламәтлеген тикшерүнең кертеләчәген әйткән. «Сәламәтлек саклау өлкәсе һәрбер гаиләне, гаиләнең һәрбер әгъзасын кайгыртырга тиеш», – дигән вице-премьер.

Табигатьне саклаучылар күбәя

Татарстан кәгазь калдыклары җыю буенча иң актив 5 төбәк исемлегенә кергән. Чара «Экология» илкүләм проектын хуплау максатында «БумБатл» бөтенроссия акциясе кысасында уздырылган.

Экология министры урынбасары Егор Тарнавский әйтүенчә, акция 10–15 ноябрь көннәрендә үткәрелгән. Шушы вакыт эчендә республикада яшәүчеләр барлыгы 185 тонна макулатура җыйган. 11 ноябрьдә генә дә Казанның «Мега» сәүдә үзәге парковкасында 1 тонна кәгазь һәм катыргы калдыклары эшкәртүгә тапшырылган.

Исегезгә төшерәбез: республикада табигатьне саклау максатыннан уздырылган чаралар нәтиҗәсендә экологиягә сак карашлы кешеләрнең өлеше 34,7 процентка (1 миллион 388 мең кеше) җиткән. Чагыштыру өчен: 2022 елда мондыйлар саны – 1 миллион 320 мең, 2021 елда 1 миллион 285 мең генә булган.

Курку файдага булган

Республикада бер ир-атның алимент буенча бурычы 1 миллион сумга җиткән. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, Балтач һәм Кукмара районнары буенча суд приставлары бүлегендә эшләүчеләрдән ул төрлечә качып йөргән. Аны административ җәза чарасына тартып, җинаять җаваплылыгы турында кисәткәннәр. Әмма ваемсыз ир барыбер бурычын түләргә ашыкмаган.

Нәтиҗәдә аңа карата җинаять эше кузгатканнар. Юньсез ата, бу юлы инде төрмә «исе»н сизеп, 1 миллион сумлык бурычын түләргә мәҗбүр булган.

Сак бул!

Карап атлыйсы

Бу көннәрдә Татарстан травмпунктларыннан кеше өзелми. Көннәр суытып, аяк асты боз белән каплануга, республикада имгәнүчеләр саны ике тапкыр арткан. Бер травмпунктка көненә уртача 15ләп кеше мөрәҗәгать итә.

Барысында да диярлек бер гозер – кемдер бозда таеп егылып, оча-бот һәм муен сөяген сындырган, кулын каймыктырган. Бөтен республикада шул хәл. Әлмәттә ике көн эчендә бозлавык аркасында 100дән артык кеше имгәнгән. Түбән Камада бозлавык аркасында бер көн эчендә 20 кеше зыян күргән.

12 нче шәһәр хастаханәсе травматологларының да бу көннәрдә эштән бушаганнары юк. Көненә 80ләп кешегә ярдәм күрсәтә алар. Имгәнүчеләр арасында 35–60 яшьлекләр күбрәк. Әле бер ай элек кенә 58 яшен тутырган Надия Гарәпшина – шуларның берсе. Кисәк суыткан беренче көнне үк бозлавык корбаны булган ул.

– Кибеткә барырга дип чыккан идем. Подъездан ерак китәргә дә өлгермәдем, аягым таеп, дөмбердәп, бозга килеп төштем. Тору түгел, селкенә дә алмадым. Узып баручылар ашыгыч ярдәм чакыртты. Сул кулым сынган булып чыкты. Унбиш ел элек шулай бозлавык аркасында уң кулымны сындырган идем инде, – ди ул.

Табиб-травматолог Булат Вахитов сүзләренә караганда, кеше күбрәк өйдән чыгуга ук имгәнә икән.

– Гадәттә, кеше егылганда кулына таянып калырга тырыша. Шуңа күрә имгәнүчеләр арасында кулы сынучылар күп. Бот, муен сөяге сыну, кул каймыгу очраклары да шактый, – ди табиб.

Балалар арасында да имгәнүчеләр күп. Республика клиник балалар хастаханәсенә узган атнада 20 баланы алып килгәннәр. Аларның күбесе урамга уйнарга чыккач имгәнгән. Белгечләр кышкы чорда ата-аналарга аеруча игътибарлы булырга куша. Ник дигәндә, кар ятуга балалар арасында тау шуганда, бигрәк тә «ватрушка»да җилдергәндә имгәнүчеләр саны бермә-бер арта.

Табиб-травматолог Ирек Вәлиев бозлавыклы көннәрдә аеруча игътибарлы булырга, аяк астына карап йөрергә киңәш итә.

– Аяк киеме үкчәсез, уңайлы, таймый торган, резин табанлы булырга тиеш. Бозлы юлдан барганда, аякларны җирдән аермыйча, чаңгы шугандагы кебек хәрәкәт итәргә кирәк. Имгәнү-җәрәхәтләнүләрдән саклану өчен шуннан да яхшысы юк. Куллар кесәдә булмасын. Юкса, андый халәттә егылганда баш һәм аркага зур зыян килә. Өлкән яшьтәгеләр урамга резин очлыклы кул таягы белән чыксын иде, – ди табиб.

Сүзгә-сүз

Татьяна ЛАРИОНОВА, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

Демографиягә бәйле динамика әлегә тискәре. Шул ук вакытта 2007 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 1 октябренә кадәр ана капиталына 13,5 млн сертификат бирелгән. Хәзер ул беренче балага да бирелә. Вазгыятьне үзгәртү өчен, һәр гаиләдә ике түгел, хәтта өч бала туарга тиеш. Гаилә елында күпбалалы гаиләләр турында тиешле карар кабул ителер дип көтәбез.

(«Интервью без галстука» тапшыруыннан)

РОССИЯДӘ – КЫШКЫ СПОРТ

«BestDoctor» һәм «Роза Хутор» хезмәтләре Россиядә яшәүчеләрнең кышкы спорт төрләренә кызыксынуларын белешкән. Күпләр (29%) спорт белән сәламәтлекне кайгырту максатыннан шөгыльләнсә, кайсылары (27%) вакытны файдалы үткәрүне күздә тота.



- 54% >> сноуборд
- 25% >> тау чаңгысы
- 19% >> тимераякта шуу
- 2% >> хоккей

Суыта

Татарстанда бик нык суыта. Шул сәбәпле синоптиклар 5–13 декабрь чорына кисәтү игълан иткән. Һава температурасы –34 градуска кадәр төшәргә мөмкин.

Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, чәршәмбе – 6 декабрьдә аз гына кар, буран, секундына 17 метр тизлектә җил булачак. Көндез һава температурасы –6...–11, төнлә –8...–13, урыны белән –19 градуска төшәчәк.

Пәнҗешәмбе – 7 декабрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы –20...–25 градус, төнге сәгатьләрдә –23...–29, урыны белән –34 градус күрсәтәчәк. Белгечләр басым ясап әйткәнчә, бу чорда тәүлеклек уртача температура нормадан 10–20 градуска түбәнрәк булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

НЕФТЬ БӘЯСЕ ТҮГЕЛ, ҮПКӘ ЯЛКЫНСЫНУЫ АРТА

Үткән атнада ОПЕК+ илләре нефть бәясен күтәрергә омтылды. Картельнең саммиты 26 ноябрьгә планлаштырылган иде, әмма аны көзнең соңгы көненә күчерделәр. Согуд Гарәбстаны һәм Россия кара алтын чыгаруны киметүне якласа, башка илләр моның белән килешеп бетмәде. 29 ноябрьдә дөнья матбугаты 2024 елның беренче кварталында җир мае чыгаруның 1 миллион баррельгә кимителәчәге хакында хәбәр итте. Әмма саммит булган көнне каршылыклы сүзләр таралды. Картель кабул иткән карарда элекке килешүгә тугрылык сакланачагы әйтелгән иде. Бу – квоталарның 2023 елның 4 июнендәгечә калачак дигән сүз. Димәк, яңа кыскарту көтелми. Әмма берничә минут үтүгә, аерым илләрнең үз ирекләре белән нефть чыгаруны киметәчәге турында хәбәрләр ишетелде. Россия ягулык сатуны 200 мең баррельгә киметергә вәгъдә бирде. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре – 163 мең баррель, Гыйрак – 211 мең, Кувейт – 135 мең, Казахстан – 82 мең, Алжир – 51 мең, Оман 42 мең баррель кара алтынны җир астында калдырырга җыена. 2023 елгы киметүләрне дә кушкач, ОПЕК + илләре 2024 елның беренче кварталында нефть чыгаруны 2,2 миллион баррельгә киметәчәк. Тагын бер көтелмәгән яңалык: 2024 елның 1 гыйнварыннан Бразилия ОПЕК + килешүләренә кушылачак. Хәзерге вакытта Латин Америкасының ул иле көнгә 3,7 миллион баррель нефть чыгара һәм күрсәткечен айдан-айга арттыра.

Гадәттә нефть картеле җитештерүне киметергә җыенуын игълан итү белән, кара алтын бәясе күтәрелә башлый иде, бу юлы андый хәл күзәтелмәде. Нефть фьючерслары 29 ноябрьдә баррельгә 80,5 доллар тирәсендә калды. 1 декабрьдә исә 80нән дә түбәнәйде. Согуд Гарәбстанында бюджет дефициты күзәтелә. Казнаны тутыру өчен, гарәпләргә кара алтын бәясенең, 90 доллардан ашып, 100гә җитүе кирәк. Әмма Көнбатышта башланып килүче рецессия ягулыкка ихтыяҗны киметә. Җитмәсә АКШ, Иран кебек дәүләтләр җир маен чыгаруны даими арттыра.

Европадан сагаерга мәҗбүр итә торган хәбәрләр килә. Башта алар Кытайдан гына ишетелгән иде. Кытайның педиатрия клиникалары үпкә ялкынсынулы балалар белән тулы, дигән сүзләрне имеш-мимеш категориясенә керттек. Әмма андый сүзләр Германиядән ишетелә башлады. Анда да, пневмонияле балалар саны кискен арта, диделәр. Дүшәмбе иртәсендә Дания, Франция, Нидерланд, балалар арасында үпкә ялкынсынуы рекордлы дәрәҗәгә үсә, дигән хәбәр тараттылар. Табиблар ниндидер яңа вирус турында бернәрсә дә әйтми. Ковидка каршы вакциналаштыру иммунитетны бетерде, дигән рәсми үк булмаган сүзләр генә йөри...

Россиядә

ЭШЧЕ КУЛЛАР КИМИ

Росстат 2023 елның гыйнвар – октябрь айларында Россия икътисады турында күңелгә ятышлы мәгълүматлар игълан итте. Илнең эшкәртү тармагы көчле үсештә. Мебель җитештерү – 145,7 процентка, автотранспорт чаралары һәм прицеплар – 141, металл эшләнмәләр – 134,5, компьютерлар, электрон һәм оптик эшләнмәләр – 131,4 процентка, электр җиһазлары җитештерү 125,4 процентка арткан. Гадәттә элекке җитештерү бик түбән булганда гына шундый кискен үсеш темплары күрсәтеп була. Импорт кимү сәбәпле, үзеңнекен эшләүне арттырасың. Шулай да товарны үзеңдә җитештерүгә күчү – сөенечле күренеш. Экспортның үсүе турында да кызыклы хәбәрләр бар. Быел 10 айда Россиядән Гонконгка алтын сату 10 тапкыр үскән һәм рекордлы күрсәткечкә ирешкән. Барысы 5,31 миллиард долларлык алтын озатылган. Октябрь аенда Гонконгка алтын сату күләме 987,6 миллион долларга җиткән. Бу Россиянең ул илгә 2022 елгы барлык алтын экспортыннан артыграк. Россия алтыны Кытайның алтын запасын тулыландыруга хезмәт итә. Моңа шатланыргамы, кайгырыргамы икәнен аңлау гына кыен.

Россия тагын бер өлкәдә кызу үсеш темплары күрсәтә: безнең тавыклар салган йомырка бәясе Америка тавыкларыныкы белән тигезләште. Американнарның хезмәт хаклары безнекенә караганда күп тапкырлар артык, бу өлкәдә аларны куып җитеп булмый әле. Әмма йомырка бәясе белән озакламый борыннарына чиертербез кебек. Автор карады: бер атна эчендә Татарстанда йомырканың бәясе, 5,22 процентка артып, дистәсе 104,68 сумга җиткән. Бу – гиперинфляция темпы. Яшел Үзәндә бер дистә йомырканы 124,8 сумга сатып, барысын да уздырганнар. Монополиягә каршы федераль хезмәт үткән җомга санындагы безнең язманы укыган: йомырка бәясендәге сәүдәгәрләр өлешен 30 проценттан 5кә калдыру турында тәкъдим ишетелде. Бу бәяне 25 процентка киметер иде, ләкин әлегә изге теләк булып кына кала.

Россиядә эшче куллар җитешми. 2030 елга кадрлар дефициты 4 миллион кешегә җитәчәк, диләр. Җитмәүчелекне мөһаҗирләр белән дә каплап булмаячак. Алар тагын өстәмә 400 мең кеше генә бирә алачак. Федераль хөкүмәт киләсе елга мигрантлар квотасын чирек тапкыр арттырды. Мәскәүдә баласызлык өчен махсус салым кертү идеясен байрак итеп күтәрәләр. Совет чорында бу юлларның авторы, өйләнеп, улы туганчы түләде ул салымны.

ТАМЫРЫ БАР, БАЛТА КИРӘК

Татарстанга яңа билгеләнгән баш прокурор тәүге мәртәбә журналистлар алдында чыгыш ясады. Нәрсә турында хисап тотты, дисезме? Ришвәтчелек һәм аңа бәйле күренешләр турында сөйләде. «Минем монда шәхсән чыгыш ясавыма карап, әлеге мәсьәләнең минем өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын аңлагансыздыр, шәт», – дип кисәтеп куйды Альберт Суяргулов. Балык йокламасын өчен, күлдә чуртан кирәк шул. Монысы да – прокурор сүзе.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанда ришвәтчелеккә бәйле җинаятьләрдән күрелгән матди зыян күләме 3 млрд сумнан артып киткән. Әмма моңа карап кына республиканы ришвәтчелек чәчәк ата торган төбәкләр исемлегенә кертмәскә. Альберт Суяргулов шулай ди. Эш бара бит: гаеплене тоталар, җәзасын бирәләр.

Ел саен Татарстанда бер меңнән артык коррупцион җинаятьләр фаш ителә. Суд хөкеменә 800 очрак буенча 230 җинаять эше юлланган. Агымдагы елда республика судларына ришвәт һәм коррупцион җинаятьләрдән килгән зыянны түләтү турында 63 гариза бирелгән. Казна файдасына алардан 450 млн сумнан артык акча түләттерергә мөмкиннәр.

Прокурор әйтүенә караганда, быел ришвәтчелектә федераль, төбәк, муниципаль дәрәҗәдәге вазыйфаи затлар да тотылган. Әйтик, Социаль иминиятләштерү фонды, Әлмәт, Тукай районнарының башкарма комитеты, Казан медицина көллияте хезмәткәрләре.

– Ришвәтчелек тамыры бюрократиянең артык булуына, закондагы «ак тап»ларда, чиновникларны күзәтү-контроль системасының нәтиҗәсезлегендә ята, – ди прокурор.

Ришвәтчелек дигәндә, акча алыш-бирешен генә түгел, закон кысасына сыймаган башка кырын эшләрне дә күздә тотарга кирәк, ди прокурор.

Кырын эшләрдә 600ләп вазыйфаи зат тотылган быел. Алар дисциплинар һәм административ җаваплылыкка тартылган.

– Ришвәтчелек аеруча да мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль хезмәт күрсәтү, дәүләт сатып алулары, торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы, төзелеш өлкәләрендә еш очрый, – дип санап үтте Альберт Суяргулов.

Җитәкче урынын биләгән затлар арасында кырын эшләр күплеген исә прокурор болайрак аңлатты:

– Бер мәлне барысы да иркенәеп китте. Шуннан барысы да ачыкланды инде. Балык йокламасын өчен, күлдә чуртан кирәк шул, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сан

Татарстанда – ришвәтчелек
- **418** ришвәтчелек очрагы
- **137** – ришвәт алу
- **186** – ришвәт бирү
- **94** – ришвәтчелектә арадашчылык
- **230** – вак-төяк ришвәт очраклары
- Ришвәт суммасы (уртача) – **263 мең** сум (узган елгы суммадан **80 мең**гә күбрәк)

КАЙБЕР МИСАЛЛАР

- Ышаныч югалту сәбәпле, Менделеевск районы башлыгы ярдәмчесе эшеннән алынган. Баксаң, ул үзе дә районда ришвәтчелеккә каршы көрәш буенча җаваплы кеше саналган, ди.
- Әлмәт районы башкарма комитеты начальнигы да вазыйфасыннан азат ителгән. Аңа карата җинаять эше ачылган. Ул махсус хәрби операциядә катнашучыларга дигән сылтау белән эшмәкәрләрдән акча җыя торган булган.
- Республика буенча Эчке эшләр министрлыгының бер вәкилен дә эштән алганнар. Ул үзенең керемнәре турында тулы мәгълүмат җиткермәгән.

Волейболчылар бәйрәм итә

«Мәктәп волейбол лигасы» республика проектына – 5 «яшь». Бу уңайдан Казанда тантаналы чара узды. Проектта катнашучыларны, волейбол сөючеләр, спорт җәмгыяте вәкилләрен Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

Дәүләт Советы Рәисе, бәйрәмне ачып, 2018 елда Федерация президиумы утырышында мәктәп волейбол лигасын булдыру турында карар кабул ителүен искә төшерде. Проектның максаты укучыларны волейбол хәрәкәтенә җәлеп итү иде. «Вакыт карарыбызның дөреслеген раслады, – дип басым ясап әйтте парламент башлыгы. – Мәктәп волейбол лигасы хәрәкәте барлык муниципаль берәмлекләрдәге 740 мәктәптән 5–11 сыйныфларда укучы 27 меңнән артыграк баланы берләштерде».

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, республикада 47 меңнән артыграк кеше волейбол белән шөгыльләнә. Бүген Мәктәп лигасы – 5 меңгә якын команда ул. Алар уку елы дәвамында 10 меңгә якын уенда катнаша. «Балалар, ата-аналар, укытучы, тренер, судьялар, профессиональ клублар, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, иганәчеләр волейбол аша укучыларны спортка, сәламәт тормыш рәвеше алып баруга җәлеп итү максатында бер йодрыкка туплана, – диде Волейбол федерациясе президенты.

Парламент Рәисе республикада спортка ярдәм итүгә кагылып, профессиональ командаларыбызның зур уңышларга ирешүен билгеләп үтте. «Узган сезонда «Зенит-Казань» командасы, Россия кубогын яулап, янә ил чемпионы исеменә лаек булды, ә «Динамо-Ак Барс» командасы Суперкубок отты, – дип билгеләп үтте ул. – Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәмендә барлык шәһәр-районнарда заманча спорт корылмалары булдыруга ирешелде. 286 универсаль спорт залы эшли, 17се соңгы 4 ел эчендә төзелгән. 34 спорт мәктәбе һәм волейбол бүлекләрендә 5 меңгә якын яшь спортчы үзенең осталыгын үстерә. Сәнәгать предприятиеләре, дәүләт оешмалары хезмәткәрләре, төрле яшьтәге ветераннар волейбол уйный. Федерация һәр ел саен 120дән артыграк волейбол турниры уздыра».

Фәрит Мөхәммәтшин республика шәһәр-районнары җитәкчеләрен балалар һәм яшьләр арасында волейболның популярлыгын үстерергә, аны иң киң таралган спорт төренә әйләндерергә өндәде. «Мәктәп волейбол лигасына даими ярдәм итәргә, физкультура укытучыларын, спорт мәктәпләре тренерларын шуңа җәлеп итәргә кирәк», – дип билгеләп үтте парламент башлыгы.

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе коллективына; «Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе Казан православие дини семинариясе» дини оешмасы – дини югары белем бирү мәгариф оешмасы хезмәткәрләре: иерей, дини тәгълимат һәм философия кафедрасы өлкән укытучысы **Варнашов** Валерий Евгеньевичка, иерей, гомуми тарих һәм чиркәү тарихы кафедрасы доценты **Ермошин** Антон Владимировичка, иеромонах, дини тәгълимат һәм философия кафедрасы өлкән укытучысы **Забавнов** Сергей Сергеевичка, читтән торып уку бүлекчәсе мөдире **Земцева** Екатерина Геннадьевнага, иерей, беренче проректор **Кузнецов** Никита Сергеевичка, ислам дин белеме кафедрасы укытучысы **Рогатина** Елена Сергеевнага; Казан шәһәр Думасы аппаратының мэр ярдәмчесе – баш эксперты **Сәлахов** Марат Фарук улына; **«Бәрәкәт-Благо» хәйрия фонды коллективына**, **«Зәкят» хәйрия фонды коллективына**, **«Урал аръягы татарлары» Курган төбәк иҗтимагый оешмасы коллективына**, **«Төмәнәк» татар иҗтимагый тарихи-мәдәни үзәге» җирле иҗтимагый оешмасы коллективына**, **Нижневартовск шәһәренең «Мирас» татар милли-мәдәни мохтарияте җирле иҗтимагый оешмасы коллективына**, **Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасының Курган өлкәсе Шадрин районы Йолдыз авылы мөселманнары җирле дини оешмасы коллективына**, **В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте коллективына**, **«Оренбург татар милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы коллективына**, **Мәскәү шәһәренең татар милли-мәдәни мохтарияте төбәк иҗтимагый оешмасы коллективына**, **«Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте составындагы Удмуртия мөселманнары төбәк Диния нәзарәте» дини оешмасы коллективына**, **Самараның «ДУСЛЫК» төбәк иҗади иҗтимагый оешмасы коллективына**, **Самара шәһәренең татар милли-мәдәни мохтарияте коллективына**, **Ульяновск өлкәсе татар эшмәкәрләренең «Сембер» иҗтимагый оешмасы коллективына**, **Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы коллективына**, **Чувашстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы коллективына**; **«АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) коллективына**; **«Вакуммаш» акционер җәмгыяте коллективына**, **«Чистай Автодор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, **«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе коллективына Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

СӨТ КҮП – АКЧА ЮК

Районнардагы сөт хаклары турында күпме генә язсак та, артык булмас. Чөнки алар әледән-әле үзгәреп торучан. Дөрес, ел башыннан бик тиз һәм шактый түбәнгә тәгәрәгән сөт хаклары август ахырларында бераз күтәрелеп алды да үсеш тукталды. Хәзерге вакытта республикада халыктан җыела торган сөтнең уртача бәясе 24,30 сумны тәшкил итә. Тик шул ук вакытта сөтне 30 сумга сатып алучылар да, 20 сум гына түләүчеләр дә бар. Районнардагы вазгыятьне белештек.

Кайбыч районының Чүти авылында яшәүче Лилия һәм Дамир Насретдиновлар хуҗалыгында бүген уникe сыер савыла. Әле җәй көне генә аларның баш саны егерме ике булган. Тик сөт бәяләре төшү үз эшен эшләгән – терлекләрен азайтырга карар кылганнар.

– Ноябрьдә сөтне 18 сумга саттык. Җәен бөтенләй 15 сум иде. Шуңа күрә егерме ике сыердан уникегә калдырдык. Акрынлап тагын да киметергә уйлыйбыз. Сөт арзан, терлек азыгы кыйммәт. Сыерлардан тыш, бозаулар, үгезләр бар, – ди хуҗабикә.

Гаилә башлыгы Дамир Насретдинов фикеренчә, сыерга караганда үгез асрау отышлырак.

– Сыерларны мал чалу цехына 370 сумнан тапшырдык. Сөт бәясе бигрәк юк бит. 30 сумнан башта 15кә калды, хәзер 18 сум. Аның нинди файдасы булсын? Сөткә бәя яхшы булганда, рәхәтләнеп асрадык, авырсынмадык. Ничек тә тырыштык. Менә хәзер бик авырлашты. Чыгымы зур, кереме кимеде. Кредитка техникалар да сатып алдык, алар үзләрен акламаячак, әлбәттә. Сөтнең бәясе уйнаса да, итнеке тотрыклырак, – ди ул.

Терлек, бигрәк тә сыер малы асрауның отышсыз булуын саннар белән дәлилләп күрсәтте ул.

– Ноябрьдә унбиш көнгә 20 мең сумлык сөт тапшырдык. Сыерларга көнгә бер рулон печән кирәк. Анысын 1500 сумга сатып алдык. 40 кг фураж ашыйлар. Ветеринария хезмәтләренә генә елына 50 мең сумга якын акча тотыла. Ягулыгын, запас частьлар алуны, кул хезмәтен исәпкә алсаң, асрап азапланмаска кирәк. Сөткә бәя булса, сыерны бетермәс идек. Сыеры булса, бозавы, ягъни үгезе я танасы була дигән сүз бит инде. Ә сыер булмаганда 2 центнерлы үгезне 50 мең сумга сатып алырга кирәк, – ди Дамир Насретдинов.

Кама Тамагы районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Илфат Вәлиев фикеренчә исә, халыкның сыерларын бетерүенә сөт бәясенең бернинди дә йогынтысы юк.

– Мин бервакытта да аларны бәйләп караганым булмады. Сөт бәясе биш елдан биш елга гел шулай уйнаклый. Безнең районда да сыерларны бетерәләр, тик аларның барысы да диярлек – өлкән яшьтәгеләр. Яшьләр дә бар, тик алар алай ук күп түгел. Җидешәр-сигезәр сыер асраучысы да бар, – диде ул.

РАЙОННАРДА ҖЫЕЛА ТОРГАН СӨТКӘ УРТАЧА БӘЯЛӘР



Идарә башлыгы сүзләренчә, бүген районда гади халык сөтне 22 сумнан алып 24 сумга кадәр бәядән тапшыра. Фермерлардан 24 һәм 26 сумга җыялар.

– Хуҗалыкларда сөтнең үзкыйммәте – 29–30 сум. Шуңа күрә аның бәясе 30 сумнан да кимрәк булырга тиеш түгел, дип саныйм. Монда табыш турында сөйләп булмый бит. Ашлык бәяләре кимеде, дисәләр дә, катнаш азык, печән, силос, ягулыкныкы артты, – диде Илфат Вәлиев.

Апас районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Радик Гыйсмәтов әйтүенчә, кооперативлар халыктан сөтне зуррак хакка җыя. Тик таләпләр дә катгыйрак.

– Сөтнең сыйфатына игътибар бирәбез. Бәяне дә шуңа карап түлиләр. Кооперативларда зуррак бәя тәкъдим ителә. Шуңа күрә районда аларны мөмкин булганча күбрәк төзү буенча сөйләшүләр алып барабыз. Ә халыктан төрле кешеләр җыя торган сөт бәяләре аерыла. 20 сумга җыючылар да, 25 сумга тапшырган кешеләр дә бар, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЭШ ҺӘМ АШ

«Татар-информ»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Милли йолалар димәктән, Татарстан ВДНХга килгән халыкны «Каз өмәсе» белән шаккатырды. Кызлары да, казлары да – Мөслимнән. Татпотребсоюз оештырган мәйданда Тулада махсус ясалган 2,3 метр биеклектәге самавырда су кайнатып, кунакларны шифалы чәй белән дә сыйладылар. Ул гына да түгел, 1200 литр сыйдырышлы казанда 4 мең кешегә җитәрлек каз шулпасы пешергәннәр. «ВТ» хәбәрчесе дә татып карады: тәмле. Казы – Мөслимнән, бәрәңге белән кишерен исә республиканың төрле районнарыннан җыйганнар. Сүз уңаеннан, Россия кухнясы йортында Татарстаннан килгән иң яхшы аш-су осталары эшләде. Тәм-том белән сыйлап кына калмадылар, чәкчәк, талкыш кәләвә һәм башка ризыклар пешерергә дә өйрәттеләр.

Безнең җыр

Татарстан көне ВДНХда 5 урында тәкъдим ителде. Җир шары рәвешендә ясалган республика стендында иртәдән кичкә кадәр викторина һәм лекцияләр дәвам итте. Биредә татарча да сөйләшергә өйрәттеләр, ислам финанслары турында да сөйләделәр. Мәдәни комплекста татарча биюләре, җырмоң белән сөендерделәр. Монысы Мәскәүдә яшәүче милләттәшләребезнең күңеленә аеруча хуш килде. «Инде 42 ел Мәскәүдә яшибез. Бу күргәзмәне оештырган милләттәшләремә бик зур рәхмәт! Концерт та искиткеч булды, туй йоласын карагач, яшьлеккә кайткандай булдым. Халкым белән горурланам. Мәскәүдәге татарча спектакль һәм концертларны калдырганым юк. Туган нигездә 92 яшьлек әтиебез яши. Әле ике атна элек кенә кайтып килдек. Туган якка, әти янына еш кайтам», – дип сөйләде Рүмзия Гайнуллина «ВТ» журналистына.

Кайту димәктән, Татарстан көнендә республикадагы туризм мөмкинлекләренә аерым игътибар бирелде. Кунакларга киләсе елда узасы «Киләчәк Уеннары» турында сөйләделәр. Республика стендында, махсус шлем кидереп, Казан урамнары буенча сәяхәткә алып чыктылар. Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов «Туризм» павильонында «Бөек Болгар юлы», «Казань марина», тизйөрешле «Метеор» проектларын тәкъдим итте. Мәдәният министры Ирада Әюпова да Татарстанга кунакка чакырды. Күрсәтерлек урыннар күп, кыскасы. Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина исә республиканың халыкара чаралар уздыру үзәгенә әверелгәнен әйтте. Татарстанның спорт министры Владимир Леонов Олимпия чемпионы Алинә Заһитова исемен йөртәчәк фигуралы шуу мәктәбе турында сөйләде. «Киләсе елда барыгызны да Казанда көтәбез», – диде Владимир Леонов.

Бу көнне Мәскәүдә татарлар җыелган тагын бер урын Салават концерты булды. Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Россия башкаласындагы иң зур кунакханәләрнең берсендәге концерт залында чыгыш ясады. Ике мәртәбә. Тамашадан соң кунакханә тирәсе август аендагы Камал театры мәйданына охшап калды. Кайтып баручы җыр сөючеләрне «ВТ» хәбәрчесе дә очратты. «Апалар, егыла күрмәгез», – дигәненә аларның җавабы мондый булды: «Борчылма, энем! Мәскәүдә безне берни ега алмый!»

«Россия» Халыкара күргәзмә-форумы, Мәскәүдә 4 ноябрьдә ачылып, 2024 елның 12 апреленә кадәр дәвам итә. Биредә Россиянең 89 төбәгенең, зур компанияләр, министрлыклар һәм оешмаларның казанышлары тәкъдим ителә.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

«Балтачта да туй итәчәкбез»

«Туебызда моның кадәр кунак булыр дип уйламаган идек!» Туйларын Мәскәүдәге «Россия» күргәзмә-форумында уздырган Зыятдиновлар әнә шулай ди. Аларның куанычын йөзләгән кеше уртаклашты.

Яшь гаилә башлыгы Самат – гаиләдәге биш бала арасында иң өлкәне. Сөмбелнең исә тагын ике бертуганы бар. Мәскәүгә дә алар зур гаиләләре белән бергә килгән.

– Монда 14 кеше килдек. Гаиләләребез зур, шөкер. Туганнарыбыз күп, алар белән бергә 23 декабрьдә туган ягыбыз – Балтачта да туй мәҗлесе уздырырга ниятлибез, – дип сөйләде безгә Сөмбел. – Шөкер, Татарстанда йолаларыбыз әле дә яши, яшь парлар аларны үтәргә тырыша. Без дә аларны бик яхшы беләбез, берсе дә яңалык булмады. Монда да чын дөреслекне күрсәттек.

Сөмбел белән Самат – сыйныфташлар. Хәзерге вакытта Самат Казан авиация институтында белем ала. Булачак инженер-конструктор. Сөмбел Казан илкүләм тикшеренү технология университетында магистратурада укый, кафедрада эшли. Киләчәктә шунда калып, студентларга белем бирергә ниятли.

– Кыскасы, Татарстаннан беркая да китәргә җыенмыйбыз. Республикада яшьләргә бер дигән мөмкинлекләр бар, – ди Сөмбел.

Үзләрен котлаган һәркемгә рәхмәт әйтте яшьләр. «Туебызга моның кадәр кеше килер дип уйламаган идек! Аны шушы рәвешле уздырырбыз дип тә хыялланмадык. Һәркемгә рәхмәт!» – диде алар.

ИРТӘГӘ БҮГЕННӘН БАШЛАНА

Яшәргә өйрәнәбез

Татарстанда кайсы өлкәгә игътибар җитми? Моны республикада яшәүчеләр үзләре хәл итә. Татарстанда 2024 елга өстенлекле бурыч-максатларны сайлау буенча онлайн тавыш бирү дәвам итә. Әлеге эштә республикада яшәүче 20 меңнән артык кеше катнашкан инде.

Татарстанда, халык фикеренә таянып, республика министрлыкларының өстенлекле бурыч-максатларын билгеләү эше 2018 елдан бирле оештырыла. Былтыр, мәсәлән, тавыш бирүдә 37 меңнән артык кеше катнашкан булган. Соңгы мәгълүматларга караганда, 2024 елга билгеләнгән бурыч-максатларга бәйле сораштыруда республикада яшәүче 20 меңнән артык кеше тавыш биргән. Әлеге эш 6 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Тавыш бирүдә теләге булган һәркем катнаша ала. Моны Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталы яки кесә телефонындагы «Услуги РТ» мобиль кушымтасы аша эшләргә мөмкин.

Быелгы исемлектә республикадагы алты министрлыкка караган бурыч-тәкъдимнәр урын алган. «Иң элек Татарстан Иҗтимагый палатасы тарафыннан министрлыклардан билгеләнгән экспертлар үз тәкъдимнәрен җиткерде. Алга таба алар утырышларда карап тикшерелде. Шуннан соң онлайн тавыш бирүгә чыгарылды», – дип аңлаттылар Татарстан Иҗтимагый палатасында.

Халык арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләрен карап тикшергәннән соң, һәр министрлыкка иң күп тавыш җыйган биш – җиде бурыч билгеләнәчәк. Аерым алганда, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы 2024 елга 16 төрле тәкъдим җиткергән. Арада сырхауханәләрдә табиблар санын арттыру, яңа туган сабыйлар арасында үлем очракларын киметү юнәлешендәге эш тә бар. «Халыкны эш белән тәэмин итү, үсмерләрне вакытлыча эшкә урнаштыру, онкологик авыруларны иртә ачыклау, белем бирү һәм сәламәтлек саклау тармакларын кадрлар белән тәэмин итү аеруча зур кызыксыну уятты. Яшьләргә кагылышлы мәсьәләләргә килгәндә, республикада яшәүчеләрне балаларның җәйге ялы, мәдәният өлкәсендә – укучыларга төрле музейларга экскурсияләр оештыру кебек сораулар игътибарны күбрәк җәлеп итә», – диләр Татарстан Иҗтимагый палатасында. Сез дә үз фикерегезне җиткерегез!

> Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы

Бурыч – 9 нчы сыйныфны тәмамлаучылар арасында татар теленнән имтихан сайлаучылар саны 15 проценттан да ким булмасын өчен, тиешле шартлар тудыру.

Рәсимә ШӘМСЕТДИНОВА, Татарстан Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, Татарстанның халык укытучысы:

– Әгәр туган телләрне укытуны шушылай күтәрмәсәк, имтихан билгеләнмәсә, аның укытылуы әкренләп нульгә калачак. Монысы – бер. Икенчедән, укучылар туган телдән имтихан сайламый икән, Мәскәү каршында хисап торган очракта да, аларның үзләренә дә кирәк түгел, җәмгыятьтә дә әһәмияте юк, дигән фикер туачак. Өченче момент та бар әле. Укучының фәнгә мөнәсәбәте таләпләргә бәйле. Әгәр укытучы таләпчән булмаса, ул фән балада кызыксыну уятмаячак. Әти-әни дә, җитди кабул итмәгәч, баласының уңышын да, уңышсызлыгын да күрмәячәк. Туган тел үсешенә өлеш кертү – һәр кешенең бурычы. Без аны рус теле, математика һәм башка фәннәр кебек үк кеше тормышында әһәмиятле роль уйный торган предмет дәрәҗәсенә күтәрергә тиешбез. Моны кисәк кенә эшләргә дә ярамый. Бездә милли үзаң бик нык аксый әле. Әкрен генә күндерергә кирәк. Салкын суга кисәк кенә ташлаудан бернинди мәгънә дә булмаячак. Соңгы вакытта моңа бәйле сөенечле үзгәрешләр дә күзәтелә. Район башлыклары, мәктәп директорлары фәнгә бөтенләй башкача карый башлады. Укытучыларда да активлык сизелә. Буадан бер укытучы: «Төркемдәге укучыларымның яртысы татар теленнән имтихан сайлый», – диде. Алга китеш бар.

> Татарстан яшьләр эшләре министрлыгы

Бурыч – Яшь гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтүне камилләштерү

Ирина ЛУНДОВСКИХ, Чаллы шәһәрендәге «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге директоры:

– 2023 ел башына алынган мәгълүматларга караганда, республикада 14 яшьтән 35 яшькә кадәр 1 миллионнан артык кеше яши. Аларның күп өлешен студентлар һәм эшләүче яшьләр тәшкил итә. Шул исәптән, яшь гаиләләр дә күп. Яшь гаилә дигәч, без кемнәрне күз алдына китерәбез соң? Канун нигезендә, ул – гаилә коруның беренче өч елында бергә яшәүче парлар. Ир яки хатынга 30 яшь тулмаган булу да шарт. Яшь гаиләләрнең психологик проблемаларына килгәндә, алар иң элек бер-береңә яраклашуга бәйле кыенлыклар белән очраша. Гаиләдәге яңа роль, яңа туганнар, дигәндәй. Шуңа күрә үзара мөнәсәбәтләрнең ныклыгы югала. Аңлашыла ки, ир – бер гаиләдә, хатын икенче гаиләдә тәрбияләнгән. Гаиләгә, бала үстерүгә, гомумән, дөньяга карашлары төрле булырга мөмкин. Әнә шул хәлдә алтын урталыкны табарга туры килә. Еш кына озак еллар очрашып йөргәннән соң өйләнешкән парлар да гаиләдә бер-берсен тәүге тапкыр күргән кебек була. Бу исә психологик яктан болай да нык булмаган мөнәсәбәтләрне тагын да катлауландыра. Шуңа күрә гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтү эшен камилләштерүне өстенлекле юнәлеш буларак тәкъдим иттек. Чөнки җәмгыятьнең киләчәге бүгенге яшьләрнең тормыш рәвешенә бәйле.

> Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

Бурыч – социаль килешүләргә бәйле эшне көчәйтү

Артем КУЗНЕЦОВ, Татарстанның күпбалалы гаиләләре төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе:

– Социаль килешү төзеп, без фәкыйрьлекне ике мәртәбә киметә алабыз. Кешеләрнең матди хәлен яхшырту, тормышын уңайлы итү өчен, аларны эшкә урнаштырырга, үз эшләрен ачарга ярдәм итәргә кирәк. Шулай булганда гына аларның керемнәре булачак. Үз эшен ачарга теләүчеләр, килешү төзеп, дәүләттән 350 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчага өметләнә ала. Моның өчен шәхси эшмәкәр яки үзмәшгуль булып теркәлергә кирәк.

2023 елның 23 октябренә алынган мәгълүматларга караганда, авыл хуҗалыгы юнәлешендә 106 кеше социаль контракт төзегән. Үз эшен башлаган кешегә дәүләттән акчалата ярдәмнән тыш, салым түләү һәм җитештергән продукциягә хисап документлары тапшыруда да ташламалар каралган.



Илдар Мөхәммәтҗанов

> Татарстан Спорт министрлыгы

Бурыч – балаларның спорт белән шөгыльләнү мөмкинлекләрен ачыклау өчен, спорт мәктәпләрендә 6–12 яшьлек балаларны махсус программа-аппарат аша тикшерү.

Рөстәм АБЗАЛОВ, биология фәннәре докторы, профессор:

– Бу – бик мөһим эш. Спорт белән шөгыльләнергә теләгән балаларны сайлап алуда, булачак чемпионнар тәрбияләүдә ярдәмче ул. Хәзер бит ничек: барлык балалар да тренерга килә, ул барысы белән дә эшли һәм, тоемлап кына кемнең нәрсәгә хирыс икәнен ачыклый. Ул көчен дә, вакытын да бетерә. Ә бит фәнни ысул бар, аны кулланырга кирәк. Бөтен кеше дә музыкант була алмаган кебек, спортта да сайлап алу кирәк. Без бит: «Юк, сез бу спорт белән шөгыльләнмәгез, якын да килмәгез», – димибез, ә киңәш буларак: «Болайрак итегез, монда барыгыз, сәламәтлек өчен шөгыльләнегез», – дибез. Бу – чикләү түгел, киресенчә, балаларның сәләтен ачыклау өчен нәтиҗәле ысул. Моны ата-аналар да аңларга тиеш.

> Татарстан Мәдәният министрлыгы

Бурыч – Татарстан районнарының үзәкләштерелгән клуб системалары базасында ким дигәндә ике халык сәнгать кәсепләре остаханәсе ачу.

Гөлназ ЛАТЫЙПОВА, Татар мәдәни ресурс үзәге директорының фән һәм нәшрият эшчәнлеге буенча урынбасары:

– Республикабызның халык сәнгате һөнәрләре тирән тарихи тамырларга ия. Традицион технологияләрне үсеп килүче буынга тапшыру һәм саклау – иң мөһим бурычларның берсе. Хәзер җәмгыятьтә кулдан эшләнгән продукция, шул исәптән көнкүреш товарлары, аеруча милли костюмнар белән кызыксыну сизелә. Авыл җирлекләрендә эшләп килүче мәдәни-ял итү учреждениеләре бу өлкәдә гаять зур эш алып бара. Мисал итеп, тал үрү цехы, керамика, туку, зәркән остаханәләре ачуны атап узарга мөмкин. Районнарда санап үтелгән юнәлешләр буенча һөнәрчелек үзәкләре ачу безнең җирлеккә генә хас борынгы һөнәрләребезне саклап калу, популярлаштыру, аларны торгызу мөмкинлеген бирәчәк.

> Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы

Бурыч – яңа туган балалар арасында үлем-китем очракларына киметү һәм 15–17 яшьлек балаларның репродуктив сәламәтлегенә игътибарны арттыру.

Лилия МӨХӘММӘТГАТОВА, 10 нчы номерлы шәһәр балалар хастаханәсенең баш табибы:

– Яшь буынның киләчәге, сәламәтлеге турында сөйлибез икән, без, иң беренче чиратта, кыз һәм малайларның саулыгын кайгыртырга тиеш. Аларның репродуктив сәламәтлеге турында мәктәптә укыган чорда ук яхшылап уйларга кирәк. Шуңа күрә киләсе елда 15–17 яшьлек кыз һәм ир балаларның гинеколог һәм урологларга күренеп тору күрсәткечен 78 проценттан 83 процентка җиткерәсе иде. Гомумән, һәркемнең үз сәламәтлегенә игътибарлырак булуын телибез. Диспансеризация вакытында да күпме чирне алдан кисәтеп, күпме авыруны вакытында дәвалап, җиңеп була. Табиблар һәрдаим әйтеп, кисәтеп торган киңәшләргә колак салучы гына сирәк. Хәле уңайлануга, барысы да истән чыга. Әйтик, кешегә гипертония диагнозы куелган икән, ул табиб әйткәннәрне һәрчак истә тотып, даими дәваланып торырга тиеш. Сәламәтлекне килеп терәлгәч кенә кайгыртасы түгел.

Эльвира ВӘЛИЕВА әзерләде

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Бисмиллалы Европа

Кызыксынган кеше Җир шарындагы халык санының инде менә 8 миллиардка җиткәнен белә. Күпме бу, азмы, дигәндә, бу, әлбәттә, күп. Ни өчен күп? Күп, чөнки җирнең ресурслары чикле. Күп, чөнки дөньяга туган һәркемнең дә ашыйсы, кешечә яшисе килә. Ә кешечә тормыш бүген рәтле-башлы торaксыз, төрледән-төрле уңайлыкларсыз, шул ук автомобильсез була алмый. Ягъни ризыктан тыш, көннән-көн күбрәк төзелеш материалы, шул ук металл, пластик, башкасы, аларны җитештерүнең артып торуы, файдалы казылмаларны да (нефть, газ, күмер) елдан-ел күбрәк чыгару һәм ягу кирәк дигән сүз. Әлбәттә, болай кылану, экологияне исәпкә-санга алмаганда да, мәңге дәвам итә алмый. Болар барысы да билгеле бер чиккә кадәр генә.

Моннан бер гасыр элек планетада җәмгысы 1,8 млрд кеше яшәгәнен искә алганда, халык саны арту шактый ашкын темпларда: 100 ел эчендә 4 тапкыр артканбыз. Үрчү-күбәю күпчелек тарафларда, пробиркадагы микроблар тизлегендә үк булмаса да, шактый җәһәт бара. Бер үк вакытта кайдадыр кайсыдыр кавемнәр кимүдә. Африка, шул ук Көньяк Азиядә яшәүчеләр, Латин Америкасының хәтсез илләрендәге гаиләләр гадәттә күпбалалы. Ә менә Европа белән Төньяк Американың төп халыкларының үрчисе һич тә килми. (Европа турында сүз алып барганда Россияне дә искә алу дөрес, чөнки халыкның 80 процентка якыны Урал тауларының бу ягында яши.) Артмау, әлбәттә инде, проблеманы аңлаудан, җир ресурсларын сакларга тырышудан түгел. Сәбәп башкада. Икенчедән, табигать бушлыкны яратмый: кемнеңдер артып, икенче берәүләрнең кимүе шактый үзенчәлекле этнодемографик һәм дә сәяси үзгәрешләр китереп чыгара. Сүз дә шул хакта иде.

Иске Дөнья. Андагы халык санын, аның даимилеген бүген бары тик килмешәкләр, башкача әйткәндә, мигрантлар тотып тора. Ул гынамы. Моннан 15–20 еллар элек үк кайсыдыр рус телле газетада чыккан язманың исеме хәтергә уелып калган. «Европу взорвут матки арабских женщин» дип атала иде ул язма. Ягъни сугышлар, яулап алулар һич кирәкми, Франция, Бөекбритания, Голландиягә барып төпләнәсе һәм күпләп бала табуны дәвам иттерәсе генә: Европа иртәме, соңмы гарәп кыйтгасына әвереләчәк. Кыйтганы «шартлату» турындагы гыйбарәне беренче Фәләстыйнның элекке лидеры Ясир Арафат әйткән, диләр. «Шартлау» – гарәпләшү генә түгел. Ул – беренче чиратта исламлашу, менталитет алышыну.

Яхшыгамы бу хәл, әллә начаргамы, дигән сорау туа. Кистереп әйтү авыр. Җирдә кеше санын көйләү, дигәндә, яхшыга түгелдер, ә менә ислам тарафдарлары артуда, миңа калса, начарлык юк. Чөнки Көнбатыш кешесе эгоизмга чумды, «цивилизациялек»тә шуңа барып җитте: инглиз белән француз, яисә алманның, бала үстереп, аны кеше итеп интегәсе килми, ул үз көен көйләп, үзен генә яратып яшәү яклы. Андагы аксөякләр кара эшне дә ят итә. Якты, җылы офиста ак күлмәктән, галстуктан, компьютер алдында утырып эшләнгән эш кенә лаеклы санала. Бүген алар шуның җәзасын да ала: Европа, беренче чиратта гарәпләр булышлыгы белән, «каралып» бара. Африканың төньягы – Мисыр, Алжир, Ливия, Тунис, Марокко гарәпләренә муллыкка ирешкән кыйтгага җитү өчен Урта диңгез дигән «күлләвек»не генә атлап чыгасы. Сүрия, Фәләстыйн, Иордания, Гыйракта яшәүчеләрне дә ара ераклыгы тоткарламый. Гарәп дөньясына ике дистәләп дәүләт кергәнен, андагы халыкның яртысы миллиардка якынлашканын, миграция ташкынының саекмавын искәрткәндә, Европаның киләчәге чыннан да бисмиллалы күренә...

Аерым белгечләр исәпләгәнчә, милләт яисә халыкның исәнлеге гарантияләнсен өчен, һәр 100 гаиләдә ким дигәндә 212 бала туып торырга тиеш икән. Ягъни гаилә саен 2,12 сабый. Сүз, әлбәттә, дәүләтчелеге булган, ассимиляциянең ни икәнен белмәгән халыклар турында. Дәүләтсезлек өстенә теге яки бу кавем тиешле дәрәҗәдә үрчеми икән, инкыйраз тизләнә. Әгәр дә ки бүген татар авылындагы һәр татар гаиләсендә 4–5 бала тәрбияләнсә, безгә милләтнең киләчәге өчен артык кайгырасы булмас иде. Бар иде татарда ишле гаиләләр заманы. Тик бүген ул хыялда гына. Заман шундый, безнең халык та артык «акыллы»ланды, ике балалылыкны өлге итте.

Яңадан Көнбатыш Европага кайтыйк. Шул ук белгечләр 100 француз гаиләсенең – 180, инглизләрнең – 160, итальяннарның 120 бала үстерүен исәпләгән. 27 ил кергән Европа берлеге буенча гомуми сан 138не тәшкил иткән. Шпенглер бер гасыр элек үк язган «Закат Европы» менә кайда икән бит. Автор юкка икътисадый-сәяси сәбәпләр эзләгән. Барысы да эгоизм тудырган кире демографиягә барып тоташа икән бит. Россия, дигәндә, охшаш саннар юк. Тик ансыз да вазгыять ачык: татарның гына түгел, русның да саны кимүдә. Безләрдә дә, әйткәнебезчә, европалашу күзәтелә. Ана капиталы, шуңа охшаш күп төрле түләү һәм ташламалар гына хәлне үзгәртә алмый.

Демография начарлану, дигәндә, гомуми сәбәп бәлки татарга бик тә якын галим Лев Гумилевка, ул тудырган пассионарлык тәгълиматына килеп терәләдер. Аның буенча теләсә кайсы халыкның күтәрелеш, күбәю чоры булган кебек, азаю, түбәнгә тәгәрәү, ахыр килеп, бетү чоры да җитә. Европа халыклары – шактый карт халыклар. Руслар белән татарлар да күптән яшь-җилкенчәклек чорын узган. Гумилев теориясе этноска 800–1000 ел гомер бирә. Теория нигезендә, этнос проблемасыз тормышны, уңайлыклар, рәхәтне үз итте, ягъни бушану (расслабленность) халәтенә җиттеме, ул бетүгә якынлашкан дигән сүз. Кемдер: «Гарәп милләте дә егетләр яшендә түгел бит», – дияр. Анысы шулай. Тик биредә иң яшь дин – ислам факторы роль уйнамый, аларга пассионарлык өстәми микән? Ихтимал, өстидер. Ислам – диннәр арасында иң көчле, иң пассионар дин. Бәндәне шактый каты кысага куючы, аны инстинктлардан, гөнаһлы теләкләрдән ныграк аралаучы башка дин юк кебек. Тик менә ислам пассионарлыгы инде гел башка тема.

ТАГЫН НИНДИ КҮПЕР САЛАСЫ?

Миллият

Ерак араларны якынайтасы, ватандашлар, милләттәшләр белән эшен дә, бәйрәмен дә уртак итәсе. Дәүләт Советында Татарстан Рәисе каршындагы Ватандашлар эшләре буенча координация советы утырышы узды. Быел бу өлкәдә ниләр эшләнгән? Киләсе елга нинди ниятләр бар?

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанда ватандашлар белән эшнең Россиянең тышкы сәясәте кысасында алып барылуын искәртте.

– Без зур үзгәрешләр чорында, катлаулы вакытта яшибез. Бу шартларда да Татарстан милләтара татулык үрнәген күрсәтә, икътисадта тотрыклылык саклау өчен, ватандашларга ярдәм чараларын киметмәс өчен барын да эшли. Бу өлкәдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзе дә, Дәүләт Советы депутатлары да зур эш башкара, – диде парламент Рәисе.

Бу сүзләрен раслап, Мөхәммәтшин Рөстәм Миңнехановның күпсанлы эшлекле сәфәрләре вакытында төрле төбәкләрдә һәм илләрдә яшәүче татарлар белән очрашуга һәрчак вакыт табуын, депутатларның парламентара хезмәттәшлек юнәлешендә актив эшләвен атады. Моннан тыш ул Татарстанның Ислам хезмәттәшлеге оешмасына керә торган илләр белән төрле яклы элемтәләрне үстерүгә аерым игътибар бирүенә дә тукталды.

Ватандашлар эшләре буенча Координацион советның узып баручы елда башкарырга өлгергән эшләре белән Татарстанның вице-премьеры Васил Шәйхразыев таныштырды. Аерым алганда, «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре», «Җәлил укулары», «Татар кызы», «Татарча диктант» кебек чараларга һәм аларның милләттәшләрне берләштерү ягыннан әһәмиятенә тукталды. Аның докладында «Сабантуйлы дипломатия» төшенчәсе дә яңгырады.

– Кая гына барсак та, «Без сезне беләбез, Сабан туенда катнаштык, чәкчәк ашадык», – дип әйтәләр. Әмма бүген бу бәйрәм турында Мәдәният министрлыгы сөйләр, – диде Шәйхразыев. – Быел әле тагын «ифтарлы дипломатия» төшенчәсе дә барлыкка килде. 2023 елда Рамазан аенда Бөтендөнья татар конгрессы ватандашларыбыз яши торган күпсанлы җирлекләрдә ифтар ашлары уздырды.

Моннан тыш, быел Европа татарлары альянсы эшчәнлеге туктатылган диярлек, аның каравы ике яңа оешма – Гарәп дөньясы татарлары альянсы һәм Азия дөньясы татарлары альянсы төзелгән.

Татарлар – Россиядә халык саны буенча икенче урында тора торган милләт. Алар дөньяның 60 илендә гомер кичерә, шуларның 45ендә Бөтендөнья татар конгрессы үзәкләре төзелгән.

Хәзерге вакытта татар теле Россиянең 28 төбәгендә өйрәнелә. Бу хакта Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова сөйләде.

– Россия төбәкләрендәге мәктәпләрне татар телендәге әдәбият белән тәэмин итү мәсьәләсенә аерым игътибар бирелә. Дәреслекләрнең федераль исемлегенә 60 татар теле һәм әдәбияты дәреслеге кертелде, – диде ул. – Моннан тыш, агымдагы елда татар теле һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе төзелде. Татарстан методик тәэмин итү үзәге булып тора. Әһәмиятле чаралардан, быел татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия «Туган тел» форумы узды, анда Россиянең 30 төбәгеннән 800 делегат катнашты.

tatarstan.ru

Билгеле, ватандашлар белән сәүдә-икътисадый хезмәттәшлектән башка да булмый. Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Герман Лернер сүзләренә караганда, бу җәһәттән Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә республиканың дәрәҗәсен үстерү, республика предприятиеләренең продукциясен популярлаштыру, республикага инвестицияләр җәлеп итү һәм башка юнәлештә эш алып барыла.

– Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм Бөтендөнья татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе белән уртак эшебезне аерым билгеләп үтәргә кирәк. Быел республиканың рәсми делегацияләре Беларусь Республикасына, Ульяновск өлкәсенә һәм Мәскәүгә сәфәрләре барышында эшлекле даирәләр, ватандашлар һәм татар җәмгыятьләре вәкилләре белән очрашты. Ел дәвамында шулай ук Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Мисыр, Азәрбайҗан, Кытайга, Ставрополь һәм Байкал аръягы краена эшлекле сәфәрләр оештырылды, – диде ул.

Эшне туктатасы түгел! Бүген, киресенчә, тагын да активрак эшләргә, яңа «күпер»ләр салырга кирәк. Утырышта әнә шундый йомгак ясалды.

– Шул исәптән, муниципаль дәрәҗәдә эшләргә, тугандаш элемтәләр тәҗрибәсен яңадан кулланырга кирәк. Без яши торган шартларда ватандашлар белән элемтәләр тагын да мөһимрәк статуска ия, шуны онытмаска кирәк, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сан

➤ Татар мәдәниятен популярлаштыру буенча Россия төбәкләре белән **80 хөкүмәтара** һәм **39 ведомствоара** килешү имзаланган.

➤ Быел Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә барлыгы **364 Сабан туе** узган. 2024 елда **399 Сабан туе** уздырырга ниятлиләр.



Зөлфия Хәлиуллина

Сан

Районда татарларның **13,3 процент**ы, мариларның **29 процент**ы, удмуртларның **24 процент**ы туган телдә укый һәм белем ала.

БОЗ КУЗГАЛУ

Мәгариф

Милли мәгариф өлкәсендә гел ахыргы урыннарда барган Менделеевск районының әкренләп өскә үрмәләвен күрәбез. Күптән түгел анда «Мирас» татар мәктәбе ачылды. Әлеге чарада Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов та катнашты. Авыл мәктәпләрен япмаска, туган телдә укытуны сакларга тырышалар монда. Бозны кем кузгаткан?

Беренчеләр кая киткән?

Район мәгариф идарәсе башлыгы Рәис Нәҗипов белдергәнчә, Бондюг шәһәрендә (район үзәге элек шулай дип аталган. – **Авт.**) ачылган беренче мәктәптә укыту татарча оештырылган. Саный китсәк, татар зыялылары да аз чыкмаган. Әйтик, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров 3 нче мәктәптә татарча белем алган. Шунысы да гаҗәпләндерде: республика районнарында азкомплектлы мәктәпләрне күптән кыскартсалар, монда тимәгәннәр. Песәй, Абалач мәктәпләрендә 9 нчы сыйныфка кадәр барлык фәннәр дә туган телдә укытыла. Ә менә Бәзәкә, Камай авылларында татарча укытуны торгызырга җыеналар. Дөрес, бала саны гына бик аз шул. Сүз уңаеннан, быел авыл мәктәпләрендә татар, мари авылларын исәпкә алып, 1 нче сыйныфка нибары 27 бала укырга кергән.

Песәй мәктәбендә 49 бала укый. Алты авылга бу. 11 еллык мәктәп булса да, быел унынчылар юк. 1 нче сыйныфка 3 бала кергән. Барлыгы – 12 укытучы.

Мәктәп директоры Илнар Җиһангәрәев белдергәнчә, уку 9 нчы сыйныфка кадәр татарча оештырыла. «Без –татар авылы бит», – диде директор, горурланып. Математика, физика кебек фәннәрдән терминнарны татарча өйрәтәләр икән. Югары сыйныфларда исә укыту – русча. Быел 9 нчы сыйныфтагы бер укучы татар теленнән сынау сайлаган. Директор, БДИга әзерләнү өчен татарча материаллар кирәк, дип үз теләген җиткерде.

Бәзәкә мәктәбендә бүген 43 укучы белем ала. 10–11 нче сыйныфларда бер генә бала да юк. Демографиянең яхшыруына өметләнәләр. Мәктәп ремонт көтә.

«Татар» дигән сүздән башка...

Менделеевск шәһәрендә татар гимназиясе ни өчен ябылып торган соң? Моның да сәбәпләрен белештек.

Шәһәрдә татар гимназиясе 1993 елда 30 бала белән ачылган. Аның үткәне турында татар мәктәбенең элеккеге директор урынбасары Йолдыз Садыйковадан сораштык. Хәзерге вакытта ул – химия-технология лицеенда директор урынбасары. Хәер, Йолдыз Садыйкова «татар мәктәбе ябылды» дигән сүзләр белән килешеп тә бетми.

– Без татар мәктәбенә 1999 елда эшкә килдек. Ирем Марат – директор, ә мин урынбасар идем, татар телен дә укыттым. 18 ел гомеремне әлеге гимназиягә багышладым. Шуның өчен бик якын ул миңа, – ди мөгаллим. – Башта 4 нче мәктәпнең бер почмагында белем бирдек. Әти-әниләр белән очраштык, мәктәп, бакчалар буйлап укытучылар җыйдык. Нәүрүз, Сөмбелә кебек милли бәйрәмнәр уздырдык. Татар мохитенә кызыгып, балаларын китерүче әти-әниләр арта барды. Шулай итеп, укучылар саны 200гә җитте. Бездә төрле милләт балалары укыды. Барыбыз бер гаилә булып яшәдек.

2001 елда гимназияне төзекләндерелгән бакча бинасына күчерәләр. Тик 2003 елдан гимназия исемен үзгәртергә мәҗбүр була. «Татар» дигән сүздән башка гына эшләвен дәвам итә. Дөресрәге, БДИ кертелгәч, әти-әниләр, балаларыбыз югары уку йортларына укырга керә алмаячак дип, ул-кызларын рус мәктәпләренә күчерә башлый. Мәктәптә математика, физика, химия кебек фәннәр татарча укытылган чөнки. Тәрбия эше һәрвакыт татарча оештырылган. 2014 елда департамент тикшерүләреннән соң, уку йортында белем сыйфаты түбән булуы ачыклана. Ни өчен дигәндә, бирегә күбрәк зур мәктәптә укый алмаган балалар күңеленә җылылык, ниндидер яклау эзләп килә. Әмма аларның берсе дә тормышта югалып калмаган, вузларга укырга кергән.

– Без рус мәктәбенә әйләнмәдек. Гимназияне саклап калу өчен Дәүләт Думасы, Дәүләт Советына кадәр барып җиттек. Татар дигән исеме үзгәрсә дә, эчке мохит шул килеш калды бит. Ябылмады ул, без аны югалтмадык, – ди Йолдыз ханым.

2010 елда гимназия 7 нче мәктәп дип үзгәртелгән. Татар мохите сакланса да, балалар русча укыган. Ниһаять, шәһәрдә быел татар гимназиясе ачылган. Шулай ук Менделеевскига татар бакчасы да кирәк әле. Аны ачу да планнарында бар.

«Ә»не дә, «җ»не дә өйрәнерләр...

Татар гимназиясенә 1 нче сыйныфка 9 баланы кабул иткәннәр. Гомумән, бинада 170 бала укый. Әкренләп ул балалар да, үзләре теләп, татарча укырга күчәр дигән өмет бар. Хәзер югары сыйныфларга башка мәктәпләрдән дә күчә башлаганнар.

1 нче сыйныф укучыларын Рәйханә Харитонова хәреф танырга, язарга өйрәтә. Моңа кадәр мәктәптә татар теле укыткан, тәрбияче булып эшләгән ул.

– Укучыларымның күбесе – катнаш гаиләләрдән. Татарча белмиләр. Әлифбаны өйрәтәм. Аларның «ә», «җ» авазларын ишеткәннәре юк. Үзләре әйтәләр дә көлеп куялар. Татарча уеннар уйныйбыз. Туган телне өйрәтүне бурыч итеп куйдым, – ди ул.

Бу урында инде без: «Барлык фәннәр дә татарча укытылмагач, мәктәп кабат рус мәктәбенә әйләнмәсме?» – дип сорамыйча кала алмадык.

– Татарча аңламагач, фәннәрне укытуны тулысынча туган телдә оештырып булмый. Әмма әти-әниләрнең балаларын туган телдә укытасы килә. Ә сез борчылмагыз, бу сабыйлар җырлап сөйләшер, Алла боерса. Моны үз күзәтүемә алачакмын. Әгәр ничек сөйләшүләрен беләсегез килсә, тагын бер елдан килерсез, – диде безне мәктәпләр буенча озатып йөргән Рәис Нәҗипов.

Мәгариф бүлеге җитәкчесе итеп милли җанлы Рәис Нәҗиповның билгеләнүе – район өчен үзе бер табыш. Тел бетмәсен, милли мәгариф алга китсен дип тырыша ул. Аның әйтүенчә, гимназияне ачканда, татар халкының кыйммәтләренә таянганнар. Диварларда Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗевның әхлак, тел турында канатлы сүзләре эленгән. Максатлары – балаларны чын татар җанлы итеп тәрбияләү.

– Беренче шарт – балаларны Тукайлы, икенчесе – иманлы итү. Иман ул дин генә түгел, киң мәгънәгә ия. Тәрбиягә дә зур урын бирәчәкбез. «Тукай» балалар әдәби мәктәбе, «Иман» әхлак нигезләре җомга мәктәбе оештырдык. Татар көрәш мәктәбе эшли башлады. «Яшь эшмәкәр» мәктәбе ачтык. Моң да булырга тиеш. Курай мәктәбе ачу уе да бар, – диде Рәис Нәҗипов.

Район башлыгы Радмир Беляев белән дә аралашырга җай чыкты. Аннан, беренче чиратта, татар мәктәпләре турында кызыксындык.

– Без тарихи гаделлекне торгыздык. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов ярдәме белән «Мирас» татар мәктәбен ачтык. Кызганыч, ул элек ябылып торган иде. Бездә татарлар район халкының 52 процентын тәшкил итә. Шуңа күрә татарча белем бирүгә ихтыяҗ зур, – диде ул.

Радмир Беляев шулай ук татар балалары укыган Бәзәкә, Песәй мәктәпләрен төзекләндерү кирәклеген дә әйтте. Проектлар әзер икән инде.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

1 статья

1. 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 399 599 130,1 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 399 599 130,1 мең сум итеп.

2. 2025 елга һәм 2026 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2025 елга 403 592 206,9 мең сум һәм 2026 елга 427 404 227,9 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2025 елга 416 090 167,2 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 11 650 000,0 мең сум итеп, һәм 2026 елга 446 275 971,2 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 21 000 000,0 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 2025 елга 12 497 960,3 мең сум һәм 2026 елга 18 871 743,3 мең сум итеп.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2025 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген 107 714 047,3 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының иң югары чиген 8 785 346,3 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының иң югары чиген 8 785 346,3 мең япон иенасы күләмендә расларга.

2. 2026 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген 99 078 719,7 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының иң югары чиген 8 041 788,6 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының иң югары чиген 8 041 788,6 мең япон иенасы күләмендә расларга.

3. 2027 елның 1 гыйнварына:

1) Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген 89 488 992,3 мең сум итеп, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының иң югары чиген 7 298 707,5 мең япон иенасы, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча чит ил валютасында Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының иң югары чиген 7 298 707,5 мең япон иенасы күләмендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә каралган Татарстан Республикасы бюджеты ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2024 елга 6 192 920,5 мең сум, 2025 елга 5 798 328,5 мең сум һәм 2026 елга 5 387 998,3 мең сум күләмендә расларга.

5. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

6. 2024 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттән бирелгән бюджет счетында калган акчаларны тулыландыру өчен бюджет кредитлары җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашуларын башкару хокукын бирергә.

3 статья

Татарстан Республикасы бюджетында 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60^{1} статьясындагы 2 пункты нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативларын әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга керемнәр түләүләренең дифференциацияләнгән нормативларын әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

6 статья

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнарындагы дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр, 2023 ел нәтиҗәләре буенча чиста табыштан файдалану һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре карала торган хуҗалык җәмгыятьләренең идарә органнары (директорлар советы, күзәтчелек советы, акционерларның гомуми җыелышы) утырышларында карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны 2024 елның 1 сентябренә кадәр (әгәр җәмгыятьнең уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табыштан кимендә 30 процент күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә тиеш.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2023 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше 2024 елның 1 июленә кадәр әлеге табыштан 30 процент күләмендә күчерелә дип билгеләргә.

7 статья

1. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2024 елга 5 710 293,1 мең сум, 2025 елга 5 940 000,3 мең сум һәм 2026 елга 6 179 010,8 мең сум күләмендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы күрсәткечләренә 2024 елда үзгәрешләр кертү өчен әлеге статьяда расланган, бюджетлар чыгымнары классификациясенең «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегендәге «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе буенча каралган бюджет ассигнованиеләре составындагы резервланган акчаларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары буенча түбәндәгечә бүлү нигез булып тора дип билгеләргә:

1) оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымын түләүгә 2024 елга 3 720 646,6 мең сум, 2025 елга 3 794 238,8 мең сум, 2026 елга 3 899 197,6 мең сум күләмендә;

2) бюджет өлкәсе учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыруга җибәрелгән чараларны гамәлгә ашыруга 2024 елга 11 110 696,6 мең сум, 2025 елга 11 555 124,4 мең сум, 2026 елга 12 017 329,4 мең сум күләмендә;

3) аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга 2024 елга 843 187,4 мең сум, 2025 елга 963 761,2 мең сум, 2026 елга 1 839 357,4 мең сум күләмендә;

4) гражданнарның ихтыярый салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын башкаруга 2024 елга 1 352 100,0 мең сум, 2025 елга 1 352 100,0 мең сум, 2026 елга 1 352 100,0 мең сум күләмендә;

5) дәүләт (муниципаль) бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр тарафыннан дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләренә (эшләр башкаруга) дәүләт (муниципаль) йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә 2024 елга 2 950 000,0 мең сум, 2025 елга 2 950 000,0 мең сум, 2026 елга 2 950 000,0 мең сум күләмендә.

8 статья

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 2 һәм 7 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүче юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга бирелә торган субсидияләр, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга бирелә торган субсидияләр рәвешендәге грантлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә биреләләр.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78^{1} статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә торган субсидияләр, казна учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә торган субсидияләр рәвешендәге грантлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә биреләләр.

9 статья

1. 2024 елда, 2025 һәм 2026 еллар план чорында Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44^{10} статьясы нигезендә җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44^{10} статьясы нигезендә җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләме, бер кешегә исәпләгәндә, аерым муниципаль берәмлек өчен хисап финанс елында җирле бюджетның бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) һәм бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 2024 елда – 3 процентын, 2025 елда – 5 процентын, 2026 елда 5 процентын тәшкил итә дип билгеләргә.

10 статья

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

1) 2024 елга – 21 914 025,3 мең сум;

2) 2025 елга – 23 605 574,3 мең сум;

3) 2026 елга – 24 957 341,0 мең сум.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дотацияләрне 2024 елда 20 628 732,9 мең сум, 2025 елда 22 151 002,7 мең сум, 2026 елда 23 763 082,1 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырырга.

3. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә кулланыла торган муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие күрсәткечен 2024 елга – 2,264, 2025 елга – 2,264, 2026 елга 2,264 итеп билгеләргә.

5. Шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләрне исәпләгәндә кулланыла торган әлеге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкару буенча шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечен түбәндәгечә билгеләргә:

1) шәһәр җирлекләре буенча: 2024 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 644,1 сум, 2025 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 671,2 сум, 2026 елга – бер кешегә исәпләгәндә 1 423,6 сум;

2) авыл җирлекләре буенча: 2024 елга – бер кешегә исәпләгәндә 265,9 сум, 2025 елга – бер кешегә исәпләгәндә 266,9 сум, 2026 елга – бер кешегә исәпләгәндә 245,1 сум.

11 статья

1. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлүне әлеге Законга 11 – 42 кушымталар нигезендә расларга.

2. Муниципаль берәмлекләр арасында конкурс нигезендә бүленә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән субсидияләрне һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондлары исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фонды исәбеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды исәбеннән бюджетара трансфертлар булган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субвенцияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

12 статья

1. Эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 19 196 011,7 мең сум, 2025 елга 20 741 410,3 мең сум, 2026 елга 21 980 288,6 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләмен 2024 елга 10 032 649,6 мең сум, 2025 елга 10 173 038,7 мең сум, 2026 елга 10 424 434,2 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

1) мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасында билгеләнмәгән медицина ярдәменең өстәмә төрләрен һәм аны күрсәтү шартларын финанс белән тәэмин итүгә 2024 елга 1 937 252,5 мең сум, 2025 елга 1 967 270,8 мең сум, 2026 елга 1 998 723,7 мең сум күләмендә;

2) «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән очракларда чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә 2024 елга 8 095 397,1 мең сум, 2025 елга 8 205 767,9 мең сум, 2026 елга 8 425 710,5 мең сум күләмендә.

3. Әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына ай саен күчерелә дип билгеләргә.

13 статья

Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 54 204 814,6 мең сум, 2025 елга 35 801 103,8 мең сум, 2026 елга 36 029 356,8 мең сум күләмендә расларга һәм аларны тиешенчә 2024, 2025 һәм 2026 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга җибәрергә.

14 статья

Инвестиция салым кредитларын бирүгә җибәрелә торган акчаларның иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2024 елга – 100 000,0 мең сум;

2) 2025 елга – 100 000,0 мең сум;

3) 2026 елга – 100 000,0 мең сум.

15 статья

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары 2024 елда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз, моңа Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирелүгә бәйле шундый карарлар кабул итү очраклары керми.

2. Җирле үзидарә органнарына 2024 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

16 статья

1. 2024 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җирле бюджетларны финанслашу (финанс белән тәэмин итү) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган мондый бюджетара трансфертларны җирле бюджетлар акчаларын алучыларның чыгымнары буенча акчалата йөкләмәләрне түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә күчерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы вәкаләтләрен тапшыру турында карарларны Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кабул итәләр дип билгеләргә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бюджетара трансфертлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

17 статья

Татарстан Республикасы бюджетында түбәндәгеләрдән алына торган бюджетара трансфертларны һәм кире кайтарылмый торган акчаларны әлеге Законга 43 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга:

1) федераль бюджеттан 2024 елда 67 150 724,5 мең сум, 2025 елда 55 051 738,3 мең сум, 2026 елда 62 629 393,2 мең сум күләмендә;

2) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясеннән 2024 елда 247 230,6 мең сум күләмендә.

18 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

19 статья

2023 елда товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләнергә тиешле шушы дәүләт контрактларына түләү өчен файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләренең, Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар булган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2023 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый бюджетара трансфертларны бирү өчен файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләренең, финанс белән тәэмин итү чыганагы юридик затларга субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен 2023 елда кирәкле сумма чикләрендә бирелгән мондый субсидияләрне бирү өчен файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләренең калган өлеше суммасыннан артмаган күләмдәге Татарстан Республикасы бюджетының 2024 елның 1 гыйнварына калган акчалары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, 2024 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

20 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, суд эшчәнлеге турындагы, үтәтү эшен алып бару эшчәнлеге хакындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93^{8} статьясындагы 4 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча бурычны җайга салу шартларын билгели торган, акчалата йөкләмәләрне үтәүне кичектереп тору яисә аларны өлешләп түләү хакында, шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләр күләмен киметү турында ризалык килешүләре төзергә хокуклы.

21 статья

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләрдән, шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына, китерелгән зыянны ирекле рәвештә каплаганда түләнә торган түләүләрдән Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән салым булмаган керемнәр, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы белән килештереп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасының табигатьне саклау чаралары планы нигезендә әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауга һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерүне оештыруга, хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан рациональ файдалану һәм аларны яңадан торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чараларга җибәрелә дип билгеләргә.

22 статья

2024 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорга түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән дәүләт ярдәмен финанслау өлешендә;

2) «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 4 өлешенең беренче абзацының (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әлмәт муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш;

4) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш.

23 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 28 ноябрь
№ 116-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә кабул ителде

1 статья

1. 2024 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба шулай ук – Фонд) бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 79 605 662,0 мең сум, шул исәптән Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән – 68 413 312,4 мең сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан 10 032 649,6 мең сум итеп;

2) Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 79 605 662,0 мең сум итеп.

2. 2025 һәм 2026 еллар план чорына Фонд бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2025 елга Фонд бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 84 567 409,6 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 10 173 038,7 мең сум, һәм 2026 елга 89 791 229,2 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар исәбеннән 10 424 434,2 мең сум итеп;

2) 2025 елга Фонд бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 84 567 409,6 мең сум һәм 2026 елга 89 791 229,2 мең сум итеп.

2 статья

Фонд бюджетына керемнәр керүне түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2024 елга әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) 2025 һәм 2026 еллар план чорына әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә.

3 статья

Фонд бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне түбәндәгечә расларга:

1) 2024 елга әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә;

2) 2025 һәм 2026 еллар план чорына әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә.

4 статья

2024 елда Фонд бюджетын үтәгәндә әлеге Закон белән расланган күләмнәрдән тыш фактта алынган һәм максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фонд бюджетының җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертеп, бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры китереп, Фонд бюджеты чыгымнарын арттыруга җибәрелә дип билгеләргә.

5 статья

Фондның вакытлыча тотылмый торган акчаларын урнаштырудан алынган процент кереме күләмендәге акчалар Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруга җибәрелә дип билгеләргә.

6 статья

1. 2024 елга Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күләмен 8 583 510,9 мең сум итеп, 2025 елга 9 176 223,8 мең сум итеп, 2026 елга 9 790 030,9 мең сум итеп билгеләргә.

2. Нормалаштырылган иминият запасы акчалары 2024 елда түбәндәгеләргә җибәрелә дип билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруны медицина ярдәменә түләү өчен җитми торган акчаларны «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 6 өлеше нигезендә иминләштерүче медицина оешмасына бирү юлы белән өстәмә финанс белән тәэмин итүгә;

2) иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәме өчен исәп-хисаплар ясауга;

3) квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә;

4) медицина оешмаларының табибларга һәм урта медицина персоналына хезмәт өчен түләүгә тотыла торган чыгымнарын финанслашуга;

5) гадәттән тыш хәл шартларында һәм (яисә) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы белән билгеләнгән медицина ярдәме күләмнәре кимeтелүгә бәйле рәвештә медицина оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрен компенсацияләү чараларын финанс белән тәэмин итүгә.

7 статья

Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган иминләштерүче медицина оешмалары өчен мәҗбүри медицина иминияте буенча эш алып баруга чыгымнар нормативын 2024 ел өчен мәҗбүри медицина иминиятен финанс белән тәэмин итүнең җан башына дифференциацияләп исәпләнгән нормативлары буенча иминләштерүче медицина оешмасына кергән акчалар суммасыннан 0,95 процент күләмендә билгеләргә.

8 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3^{1} пункты нигезендә 2024 елда Фонд бюджетының җыелма бюджет исемлегенә әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә үзгәрешләр кертү өчен өстәмә нигезләр булып түбәндәгеләр тора дип билгеләргә:

1) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибенә үзгәрешләр кертү;

2) 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3^{2} пунктның өченче – алтынчы абзацларында каралган нигезләр буенча үзгәрешләр кертү;

3) 2024 елга бюджет ассигнованиеләрен әлеге Законда «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге, «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе, «Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү» максатчан статьясы буенча каралган бюджетлар чыгымнары классификациясе чыгымнары төрләре арасында 2024 елда чыгымнарның күрсәтелгән бүлеге, бүлекчәсе һәм максатчан статьясы буенча бюджет ассигнованиеләрен файдаланганда экономияләү хисабына яңадан бүлү;

4) 2024 елда Фонд бюджетына әлеге Закон белән расланган 2024 елга бюджет ассигнованиеләре күләмнәреннән тыш медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә җибәрелергә тиешле акчалар керү.

9 статья

Фонд бюджетының агымдагы финанс елы башына файдаланылмый калган, бюджет турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш булмаган акчалары, әлеге Законга үзгәрешләр кертмичә, Фондның җыелма бюджет язуына тиешенчә үзгәрешләр кертеп, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасында Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы үтәлешен, иминләштерелгән затларга мәҗбүри медицина иминияте полисы бирелгән Россия Федерациясе субъекты территориясеннән читтә күрсәтелгән медицина ярдәменә түләүне, квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итүгә җибәрелә дип билгеләргә.

10 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 28 ноябрь
№ 117-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

Соклану

Барысына да өлгерә

Арабызда шундый кешеләр бар: пешерсә – камыры уңа, үстерсә – яшелчәсе, сөйләшә башласа – бөтен кешене авызына карата... Бәйли, тегә, чигә... – бар эшне җиренә җиткереп, күпләр сокланырлык итеп эшли. Булганнан бар да була, дип нәкъ менә шундый сирәкләр турында әйтәләр. Авылдашым Фәнзәлия Сабирҗановага да бик туры килә бу сүзләр.

Аның чиккән, бәйләгән әйберләрен бергә җыйсаң, күзләр камашырлык тау хасил булыр иде. Әле дә бер минут тик торганы юк: телевизор караганда да, газета укыганда да кулында энәләре. Заказны биреп кенә торалар. Балалар киемнәре, башмаклар, исемнәре үреп язылган мунчалаларны бик тиз алып бетерәләр. Соңгыларына заказлар аеруча күп, бигрәк тә балалар сөенә икән мондый бүләккә. Бу бит әле аның, үзе әйткәндәй, ял иткәндә, тик утыра белмәгәнгә генә эшли торган шөгыльләре. Үз хуҗалыгы белән яшәгән авыл кешесенә йортта эш бетми. Ел саен күп итеп тавык-чебеш, каз-үрдәкне дә булдырып үстерә Фәнзәлия. Оста җиләкче, гөмбәче, пешекче дә әле ул. Блогер түгел Фәнзәлия, әмма кайчакта кызыктырып үзенең сәхифәләренә мичтә пешергән коймакларын, чиләкләп җыйган җиләк-гөмбәләрен, алардан, шулай ук бакчасында үскән җиләк-җимеш, яшелчәләрдән ясаган төрле кайнатма-салатларын куеп сокландырып ала. Бер авылда яшәп тә, аның суган үстерү белән мавыкканын үзем дә быел гына белдем.

– 1989 елда башка чыктык, ул елны әле яшелчәләр утыртырлык булмады. Икенче елны инде бакча булдырып, үзебезгә җитәрлек яшелчә үстерә башладык. Мәктәпне тәмамлагач, мин Нократ Аланында эшләдем. Анда Кукмара районының Адай авылы кызлары белән бергә яшәдек. Аларга кунакка кайткач, күп итеп суган үстерүләрен, әниләренең суганнарны баулауларын карап торып, кызыксынып, үзем дә баулап караган идем. Үз бакчабыз булгач, дусларымнан Кукмара орлыгын соратып алдым. 33 ел шул орлыктан суган үстерәм, – дип сөйли Фәнзәлия.

Дөрес, хәзер инде Кукмара орлыкларына чуаш сорты да, кызыл суган да, голланд сорты да өстәлгән. Дүрт төрле сортны – ел саен биш килограмм суган утырта икән авылдашым. Орлыкларын үзе ясый. Орлык өчен һәр сорттан иң эре, әйбәт суганнарны сайлап ала. Яз башында утырта да, орлыклары тәмам җитешкәнче, сабактан өзми. Икенче елга әлеге орлыкларны чәчеп, утырту суганы үстерә. Өченче язга инде аларны башлы суган алу өчен утырта. Менә шундый әйләнеш. Сату өчен үстерми ул аларны. Туганнарына, балаларына, танышларына күчтәнәчкә өләшә, ел саен гошергә дип тә иң эреләрен, матурларын күп итеп сайлап калдыра. Юмартлыгы бәрабәренәдер, уңышы ел да бик әйбәт була. Быел да искәрмә түгел. Инде суганнарын унҗиде пар итеп баулап элеп куйган.

– Ни өчен баулап азапланасың, сеткага, тартмага гына тутырып куйсаң, җайлы түгелме соң? – дип сорыйм.

– Баулаган суганнар әйбәт саклана. Икенчедән, бозыла башлаган суган да әллә кайдан күренә. Мин аның бер авырлыгын да күрмим. Чәч үргән кебек кенә, бик тиз һәм яратып эшлим. Кемгәдер биреп җибәрәсе булса да, бик уңайлы. Үзең дә кирәгенчә генә алып тотасың...

Гадәттә, гаиләдә я ире, яки хатыны гына һөнәрле була. Ә Сабирҗановларда барысы да алтын куллы. Мең дә бер эшне белеп-өйрәнеп туганнар диярсең. Тормыш иптәше Рафаэль бала чактан балта эшенә оста булды. Тормыш итә-итә, ташчы, калайчы... һөнәрләрен үзләштерде. Бүген инде белмәгән бер эше дә юк. Башка чыкканнан бирле бөтен төзелешне ул чакта мәктәп укучысы гына булган улы Фирзәр белән икесе эшләделәр. Кайберсен инде ике мәртәбә яңарттылар. Үзе белгән барлык һөнәрне улына иплəп кенә өйрәтүе, аны мөстәкыйль тормышка әзерләвен тирә-күршеләре һәрчак сокланып күзәтә иде. Матурлык яраткан Рафаэльнең эшләгән бар эше пөхтәлеге, уңайлылыгы белән аерылып тора. Кызлары Вәсилә дә мәктәптә укыган елларында кул эшләре буенча бик күп бәйгеләрдә катнашып, җиңүче булды. Бүген инде Фирзәр белән Вәсиләнең – үз тормышлары. Ышанам: алар да балаларын үзләре кебек һөнәрле итү өчен тырышадыр.

Тик утыра белмәгән Фәнзәлия исә барысына да өлгерә: район үзәк мәчетендә эшләп килүче мәдрәсәдә дүртенче елын инде дини белем ала, быел дипломлы булачак.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

СӨЙГӘНЕН 40 ЕЛ КӨТКӘН НУРГАЛИ ВИЛДАНОВ:

«БҮТӘН БЕРКАЯ ДА ҖИБӘРМИМ»

Язмыш

Яшьлек хаталар өчен бирелә, диләр. Нәкъ шулай. Яшьлектә кайбер мизгелләрнең кадерен дә аңлап бетермибез. Ялгышканны төшенер өчен еллар кирәк. Ярый ла хаталарны төзәтеп булса. Мамадыш районының Дусай авылында гомер итүче Вилдановларның бүген тормышлары түгәрәк. Нургали абый белән Фәридә апа 40 елдан соң янә очрашып, гаилә корып җибәргән.

Яшьлек

18 яшьлек Фәридәнең Казанда «Заря» кондитер фабрикасында эшләп йөргән вакыты. Алар тулай торакның актлар залында таныша. Икәү бергә янәшә урыннарда концерт карыйлар. Егет кызга бик ошый. Алар дуслашып китә.

– Ул чакта Нургали Казанга курслар үтәргә килгән иде. Күңелемә керде дә куйды. Күзләренә карауга ук гашыйк булдым, – дип сөйли Фәридә апа. – Бераздан Нургали – үз авылына, мин дә, әти-әнине сагынып, Кукмара районының Байлангар авылына кайтып киттем. Әмма аралар суынмый. Нургали 42 чакрым ара үтеп, яныма килер иде. Мин Кукмарада эшли башлагач, бөтенләй хисләребез артты. Бер кинодан соң Нургали абыең мине урлап та алып китмәкче иде. Көчкә үгетләп калдым. Машинасына менеп утырган идем инде. Сүземне тыңлады, ике тапкыр урам әйләндереп килде дә өйгә кайтарып куйды.

Кайтармаган булса да ярар иде! Шунда урлап алып китсә, 40 ел көтмәс иде Нургали абый! Тик язмыштан узып буламы соң?! Якутиядәге сеңлесе Халидәнең гаиләсенә кайгы килгәч, шул хәсрәтне бергәләп күтәрик, дип юлга кузгалган Фәридә шунда гаилә кора, балалар үстерә.

– Сеңлемнең яшь ярымлык баласы үлде. Кулында әле 6 айлык сабые да бар. Аның кан басымы югары иде. Бала хәсрәтен бик авыр кичерде ул. Кечкенә баласын карармын дип киткән идем. Уемда – Нургалине дә яныма чакыру

Вилдановларның гаилә архивыннан

иде. Тик ул әти-әнисен ташлап китмәде. Әмма ике арада хатлар йөри әле. Хәер, Нургали абый мин язган хатларны бүген дә күз карасыдай кадерләп саклый, – ди Фәридә апа. – Башкага кияүгә чыгуның сәбәбе – Нургали абыең бик озак хат язмый торды. Ул Сабага бер айга эшкә киткән булган икән. Миңа бик озак тоелды. Тоттым да артымнан ошатып йөргән егеткә кияүгә чыгарга ризалык бирдем.

Әмма Фәридә апа булачак иренә алдан ук әйтеп куя: Мамадыш районында сөйгәнем бар! Ире әти-әнисе Якутиягә күченеп киткән Саба егете була аның. Йөрәгендә Нургалие булса да, алар ире белән бик матур яшиләр. Ике малай үстерәләр. Ире бик акыллы кеше була. Фәридә апага мәхәббәтен исенә төшереп, йөрәген яралап тормый. Иң мөһиме – үзе ярата һәм хатынын бәхетле итәргә тырыша.

– 25 ел хәрби комиссариатта сәркатип булып эшләдем. Тормышыма шөкер итәрлек иде. Тик ирем генә озак яшәмәде. Авырды ул. Озак кына урын өстендә дә ятты. 2017 елда безне калдырып китеп тә барды. 2021 елга кадәр балаларым белән яшәдем дә улларыма туган ягыма кайтасым килгәнне әйттем. Алар каршы килмәде. Кукмарада яшәүче энем белән сөйләштем. Бар туганнарыма кайтасым килүне җиткердем. Алар сөенеп риза булды. Тәвәккәлләдем дә кайтып киттем, – ди Фәридә апа.

Кайтуга беренче эш итеп Кукмарадан бер бүлмәле фатир алып куя ул. Бервакыт Фәридә апа Алабугада яшәүче сеңлесенә кунакка бара. Машина юлы Нургали абыйлар авылы аша уза. Кайтканда, Дусайда төшүче кеше була. Фәридә апа шул хатыннан тиз генә Нургалиен сораштыра. Теләге – яшьлектәге хата өчен гафу итүне сорау. Нургалигә дип телефон язылган язу тапшыра. Көттерә әле Нургалие. Әллә хәбәре озак барып ирешә, 6 көн үткәч, Фәридә апаның телефоны шалтырый.

– «Фәридәме бу?» – дигән тавышны ишетүгә, күземнән яшь ага башлады. Әллә нишләп киттем. Әйтерсең, әле яңа гына танышкан чак. Нургалидән тизрәк гафу сорарга тотындым. Рәнҗемә, димәкче идем. Тик ул сүзне кыска тотты. Телефоннан гына сөйләшеп булмый, Дусайга килә алсаң, кил, диде. Сеңлем белән чыгып киттек. Нургали безне 4 сәгать юлда көтеп торган, – ди Фәридә апа.

4 сәгать 40 ел түгел инде! Бер дә өйләнмичә, әти-әнисен тәрбияләп яшәгән, яшьлектәге мәхәббәтенә тугры калган Нургали абый Фәридә апага кияүгә чыгарга тәкъдим ясый. Фәридә апа тиз генә җавап бирми әле. Иң элек балалары, аннан барлык туганнары белән киңәшә. Берсе дә каршы килми. «Син бәхетле икән, без бәхетле», – дип кенә җавап бирәләр.

Беренче мәхәббәт

Фәридә апа Кукмарадагы фатирын калдырып, Дусайга килен булып төшә. Ул яшерми: хисләр бер тамчы да сүрелмәгән. Еллар үткән, чәчләр чаларган, битләргә бразналар сызылган. Әмма йөрәк яшьлектә калган. Аңа әле дә Казанда Нургалие белән очрашкан вакыттагы кебек унсигез! Ә Нургали абый гомере буе Фәридәсен көтә. Сөйгәненең башкага кияүгә чыгуын кабул итеп, ялгыз яши ул. Башка берәүне дә ярата алмый. Нургали абый 45 ел буе Кыш бабай булып «эшли». Хәзер инде Фәридә апа белән бергә мәдәният йортына йөриләр. Парлап матур итеп җырлыйлар.

– Бер-беребезгә ияләнү авыр булмады, – ди Нургали абый. – Гомер буе бергә яшәгәнмени? Бергә бик рәхәт. Безнең ачуланышкан да юк. Һәр минутның кадерен беләбез. Фәридә апаң бер елмаеп җибәрә дә, миңа шул җитә инде. Бәхетле булырга беркайчан да соң түгел. Яраткан кешегезне югалтмагыз!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Табиб язмалары

ФТИЗИАТРГА ӘЙЛӘНҮ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мин медицина институтының 3 курсын Уфада укыдым. Нурихангa (язучы Нурихан Фәттах. – **Р.Ф.**) кияүгә чыккач, 4 нче курстан укуны Казанда дәвам иттем. Баштарак, яңа төркемдә укый башлагач, бераз аптырабрак та калдым. Ни өчен дигәндә, без Уфада барыбыз да бертигез идек. Башкортстанның Министрлар Советы рәисе кызы Миләүшә дә (без аны Мила дип йөртә идек), чуаш авылыннан Лиза да... Бергә колхозга җибәрәләр, бергә имтиханга әзерләнәбез. Тик каникул вакытында гына Мила әти-әнисе белән диңгез буена ялга китә, ә без инде үзебезчә – кем эштә, кем кайда. Ә Казанда 24–25 кешелек төркем икегә аерылган: берсе – патрицийлар, икенчесе плебейлар дип йөртелә. Патрицийлар өлешендә – 12–13ләп кеше, фәкать медалистлар һәм күбесе профессор балалары. Болар 2–3 курстан ук ныклап фән белән шөгыльләнәләр. Алга китеп булса да шунысын әйтергә кирәк: алар соңрак чын фән кешеләре булдылар – профессор, доцент, ассистентлар. Группаның калган өлеше – Чувашия һәм Маридан, махсус үз республикалары өчен укытырга җибәрелгән балалар.

Шулай итеп, төркемгә яңа кеше кушылды бит. Аны кая куярга? Укудагы өлгереш буенча теге яки бу группага кушып булмый, чөнки «плебей»лар арасында да отличниклар бар. Үзем берни сизмәдем, әмма мине байтак күзәткәннәр икән, анысы соңрак беленде. Кышкы сессия узгач, «патриций»лар мине үз компанияләренә кунакка чакырдылар. Ни өчен үзләренә кушарга лаеклы дип санаганнардыр, әлегә кадәр белмим.

Уку тәмамланып, дипломнар алынгач, «распределение» көтеп ректор ишеге төбенә җыелыштык. Бераздан безнең «патриций»ларның барысының да Казанда калуы билгеле булды. Бары Борис исемле бер егетебез генә армиягә алынды. Без шаулаша-шаулаша сөйләшеп торган арада, фойега кечкенә генә буйлы, бик сүзчән яшь хатын килеп керде дә безгә сүз куша башлады. Барыбызның да Казанда каласын ишеткәч, әле беребезгә, әле икенчебезгә: «Фтизиатр буласыгыз килмиме?» – дип килеп тәкъдим ясый бу. Безнең «галим» егетләребез бу сүзне ишетүгә үк әлеге апага артлары белән борылалар. «Әрсез» апа миңа да шул ук сорауны бирде. Кая ул!.. Дәүләт имтиханын бөтен фәннәрдән диярлек «5ле»гә бир дә ниндидер туберкулез табибына әйлән, имеш. Булмаганны! Әмма апа (бераздан аның республика туберкулез диспансерының баш табибы Раилә Якуповна икәне аңлашылды. Ә соңрак, инде эшли башлагач, атаклы җырчы Гөлсем Сөләймәнованың кызы икәнлеге дә билгеле булды) бик үҗәт булып чыкты, китми генә бит янымнан.

– Кем булырга соң исәбең? – ди.

– Хирург! – димен, бик горур гына.

Алтынчы курсның соңгы ярты елында хирургия бүлегендә иптәш кызым Люся белән (соңыннан шактый танылган невропатолог булды) практика үткән идек.

– Гомер буе кеше эчендә казыныргамы? Шул бүсер белән аппендициттан башка ни яңалыгы бар инде аның?! – ди бу. Аннары, минем икеләнеп калуны күреп, тагын кыза төште: – Ә менә бездә медицинаның яңа төре, торакаль хирургия (үпкә хирургиясе. – **Ред.**) бүлеге бар, менә ул ичмасам кызык!

Шулай итеп күңелгә «корт» салды да: «Иртәгә кил, үзең күрерсең», – дип ашыгып китеп тә барды.

Киләм, дип сүз биргәч, үтәргә кирәк инде. Икенче көнне Карл Маркс урамындагы туберкулез диспансерына киттем. (Ул матур йортта революциягә кадәр Казанның генерал-губернаторы яшәгән. 1921 елда бинаны туберкулез диспансерына биргәннәр. Ә хәзер ул Сынлы сәнгать музее буларак хезмәт итә. – **Р.Ф.**) Барып керү белән мине бик дәрәҗәле кешене каршылаган кебек хөрмәт белән каршы алдылар, кемдер йөгереп халат китереп бирде. Баш табиб үзе озатып, җитәкләп дигәндәй, 2 нче катка, хирургия бүлегенә алып кереп, яшь-яшь бүлек мөдире белән таныштырды. Аннары: «Киткәндә миңа керерсең», – диде дә, ашыгып китеп тә барды. Бу бүлек мөдире Владимир Андреевич Цикунов иде. Ул шул бүлектә 49 ел эшләп, әле былтыр гына пенсиягә китте. Ул көнне берничә операция-мазар күрмәдем мин. Владимир Цикунов мине бер палатага алып керде дә:

– Табиблар җитешми, барысы да ялда, менә бу палатада авырулар белән танышып чык, – диде. (Фтизиатрияда ул заманнарда да белгечләр җитмәгән, бүген дә туберкулез табибы булып эшләргә теләүчеләр бөтенләй юк диярлек. Ни өчен дигәндә, бу белгечлек буенча эшләүче табибның акчасы әллә ни күп түгел, эше сәламәтлек өчен куркыныч булса да, өстәмә-фәләннәр түләнми. Алай гына да түгел, бүгенге тел белән әйткәндә, бу өлкәдә эшләү «престижно» түгел. Авыруларның шактый өлеше, әлбәттә, барысы да түгел, тәртипсез, эчүчелеккә бирелгән яки төрмәдән чыккан кешеләр. – **Р.Ф.**)

Мин бит әле эшкә урнашмаган, болай гына килгән кеше, авырулар белән танышырга да исәбем юк иде. Әмма палатада сүз көрәштереп торып булмый, кушканны үтәргә туры килде. Таныша башлауның беренче минутында ук бер авыру:

– Мне плохо, доктор, – ди.

– Что Вас беспокоит? – дигән булдым, нәкъ институтта өйрәткәннәрне истә тотып.

– Очен плохо, слабость. Опять начинается... – диде дә бу, авыз тутырып кан коса башлады... Котым очты. Халатым, күлмәгем канга батты. Палатада ыгы-зыгы башланды. Тегеңә йөгереп килеп система куйдылар, мине исә ваннага алып кереп, тиз генә халат-күлмәкне салдырып, юа башладылар. Икенче халат киеп, күлмәгем кипкәнче шул тирәдә буталдым һәм: «Юк, монда эшләмәячәкмен», – дигән катгый карарга килеп, баш табиб бүлмәсенә киттем. Ә ул аны-моны сорашып та тормады, гариза язарга кәгазь белән ручка сузды.

– Юк, Раилә Якуповна, мин иртәгә үк эшкә чыга алмыйм. Без ирем белән иртәгә Сочига китәбез, – дидем, нинди сәбәп уйлап табарга да белмичә, аптырап. Шуннан ул минем турыда ныклабрак сораштырды да:

– Путевка беләнме? – дип сорады.

– Юк, болай гына.

– Соң, туңдырмага да иреңнән акча сорап йөргәнче, әз-мәз үз акчаң белән китү яхшырак бит инде. Ирең белән киңәш, ярар, соңыннан эшкә килмәсәң килмәссең. Хәзер берәр ай эшлә, – дип озатып чыгарып җибәрде.

Шулай итеп мин Республика туберкулез диспансерының хирургия бүлегендә эшли башладым.

Руфина ФӘТТАХОВА

ИМАН ОРЛЫГЫ

Күңел байлыгы

Әй, азан, моңлы азан, нурлы азан... Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылында үткән «Әтнә азаны» бәйгесендә катнашкан һәр баланың чыгышыннан соң күңелдә әлеге сүзләр кабат-кабат яңарды. Мондый күркәм, мәгънәле һәм халыкны берләштерүче чараның нәкъ менә бирегә узуына гаҗәпләнергә дә кирәкмидер. Түбән Бәрәскә халкы элек-электән укымышлы, зыялы, динле һәм мәгърифәтле булган. Татарстанда төзелгән иң борынгы таш мәчетләрнең берсе дә нәкъ шушы авылда бит. Җәмигъ мәчетенә 1769 елда нигез салына.

Бәйрәм башында зал тутырып килгән кунакларны Әтнә районы мөхтәсибе Наил хәзрәт Сәгъдиев сәламләде.

– Районнар арасында беренчеләрдән булып Бәрәскә җирлегендә балаларга татар азанын өйрәтү бәйгесе оештырылды. Алар үзләренең тырышлыклары да куйдылар, онлайн дәресләр дә өйрәнделәр. Без бүген матур нәтиҗәгә килеп җиттек. Балаларның барысы да җиңүче, әмма кемнәрдер күбрәк тырышлык куйгандыр, – диде ул.

Бәйге дип аталса да, оештыручылар аның мәгънәсе тирәндәрәк булуын әйтте. Белем бирү буенча махсус эшләнгән проектта районның төрле авылларыннан 42 бала катнашкан. Алар кагыйдәләрне үзләштереп, дәресләрне карап та, шулай ук остазлар белән күзгә-күз күрешеп тә шөгыльләнгәннәр. Шуннан соң жюри агъзалары азан әйткәнне төшерелгән видеоларын карап, үз бәяләрен биргән. Малайларның алтысы (Әмин Юмангулов, Ильяс Шәрипов, Әсгать Зарипов, Раяз Шакиров, Айрат Фазылҗанов, Закир Һадиев) финалга чыккан иде. Бәйрәм барышында алар сәхнәгә менеп, алган белемнәрен тамашачыга тәкъдим итте, азан яңгыратты. Олы Әтнәдән Закир Һадиев азанны барысыннан да камилрәк әйтүче булып танылды. Ул киләсе елда узачак республикакүләм бәйгегә юллама алды. Калган егетләр дә бүләксез калмады, билгеле. Һәркайсы өйләренә саллы бүләкләр, тәмле күчтәнәчләр белән кайтып китте. Моннан тыш, финалга чыккан егетләрнең барысына да үз авыллары мәчетләрендә азан әйтү хокукы бирелде.

Зөлфия Хәлиуллина

Бәйгедән берәү дә бүләксез китмәде.

«Рухи моң» иҗат берләшмәсе җитәкчесе Марсель Әхмәдуллин әйтүенчә, әлеге проектны булдыру теләге көн кадагыннан чыгып туган.

– Кызганыч, безнең халыкта азан әйтү белән бәрнекләр авырлык бар, – ди ул. – Әлеге мәсьәләне без Татарстанның атказанган артисты Марсель Вәгыйзов белән бергәләп күтәреп чыктык. Рухи моңны үстерүгә һәм Татарстан мәчетләреннән яңгыраучы азаннарның сыйфатын яхшыртуга шәхси фатихасын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм мөфтиебез Камил хәзрәт Сәмигуллин да бирде. Шушы уңайдан «Рухи моң» иҗат берләшмәсе оештырылды һәм «Татар азаны» мәктәбе төзелде.

Егетләр 2020 елда беренче азан бәйгеләрен оештырып җибәрәләр, ләкин эш барышында тагын бер мөһим мәсьәлә баш калкыта.

– Азан әйтү читтән караганда җиңел эш булып тоелса да, бик четерекле һәм авыр хезмәт. Бер генә авазны дөрес итеп әйтмәгән очракта да, аның бөтен мәгънәсе бозылырга мөмкин. Беренчедән, азан әйткәндә гарәп теле фонетикасын сакларга тиешбез. Икенчедән, аны моңга төреп бирергә һәм, өченчедән, матур тавышка игътибар бирергә кирәк. Бу шартларны бик тиз генә үтәп чыгып булмавы ачыклангач, әлеге чараны белем бирү бәйгесе дип формалаштырдык, – ди Марсель.

Ә нәкъ менә Бәрәскә җирлегендә уздыруга очраклылык ярдәм иткән диярге була. Беркөнне Марсель гаиләсе белән туган авылына кунакка кайтып барганда, тарихи мәчеткә намаз укырга туктала һәм хәзрәт аңа азан әйтергә мөмкинлек бирә. Шуннан соң авыл халкы азанны кем яңгыратуы белән кызыксына башлый. Азан әйтүченең кем булуы ачыклангач, «Ленин» хуҗалыгы җитәкчесе Илгиз Хәйруллин белән элемтәгә кереләр һәм сөйләшү барышында шушы җирлектә азан бәйгесе үткәрү буенча уртак фикергә килаләр.

– Без бу бәйгене нәкъ менә үзебезнең авылда үткәрүгә ике куллап риза булдык. Аллаһка шөкер, бүген без дөрес, матур итеп азан әйтү турында сөйләшәбез. Бу күркәм гамәлне һәр ир бала да башкарса, тормышларыбыз тагын да ямьләнер, нурланыр иде. Азан – намазга басарга бер адым. Килачәктә балалары белән бергә әти-әниләре дә дингә килергә мөмкин. Азанның моңлы да, матур да булуы төрле уйлар белән йөргән кешеләрнең бәлки колагына тагын да ныграк кереп: «Тукта, бу азанны минем өчен әйтә түгелме соң?» – дип тукталып, уйланырга сәбәп булыр. Намазларыбызны онытмасак идек, мәчетләребездә сафларыбыз артсын иде, – диде чараның оештыручысы Илгиз Хәйруллин.

Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев та мондый чараларның телебезне, динебезне, милләтебезне саклавына басым ясады. Шунысы кадерле: әлеге балалар белән эшләү алга таба да дәвам итәрләчәк.

– Балалар уңдырышлы туфрак төсле. Тәҗрибә күрсәтүенчә, алар олыларга караганда тизрәк отып ала һәм аларны, «сыгылмалы» вакытта тиешле юнәлеш биреп, иман юлына кертеп җибәрергә була. Алар алган күнекмәләр алга таба азан әйтергә генә түгел, матур итеп сөйләшергә, җырларга да юл ачар, – диде Марсель Әхмәдуллин.

Азан әйтү күнекмәләренә өйрәнүчеләр арасында Күңгәр авылыннан Алмаз Мөхәммәдьяров та бар иде.

– Без бу дусларым белән мәктәптән соң мәчеткә йөрибез. Ә бәйге турында апам әйтте. Анда катнашып, үземне сынап карыйсым килде. Бирегә мин үзем өчен күп яңалык алдым, өйрәндем, алга таба тагын да камилләшергә телим, – диде ул.

Балалар күңеленә салынган иман орлыгы киләчәктә үзенең матур җимешләрен бирер, дип телик.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КЕМ ҮСТЕРГӘН БУ БАКЧАНЫ?

Мөгаллимнәр

Чистай районының Татар Баганалысы авылы уртасында җиләк-җимеш бакчасы җәйрәп ята. Зур ул, агачлары да картаеп бара инде. Шулай булса да, яз көне шау чәчәккә күмелә. Җәй, көз көннәрендә авыл халкы татлы җимешләрдән авыз итә. Кем үстергән бу бакчаны? Авылга килгән кеше әлеге сорауны бирми калмый икән. Без дә белештек. Мондый бүләкне авыл халкына бүген Чистай шәһәрендә көн күреп ятучы Тәнзилә апа һәм Илдар абый Нигъмәтҗановлар ясаган булып чыкты. Гомерләренең күп өлешен Татар Баганалысы балаларына белем биреп, авыл халкы белән бер сулышта яшәп үткәргән бу фидакарь кешеләрнең тагын бер зур бәйрәмнәре: бергә тора башлауларына – 50 ел.

Сагынырга вакыт булмады

Олыгайган көннәрендә бар уңайлыклары да булсын дип, балалары аларга Чистай шәһәрендә менә дигән йорт салып бирганнәр. «Башта иялэшә алмый интектек. Хәзер ярый инде», – дигән булды Тәнзилә апа. И-и, ничек иялэшмисең инде мондый рәхәтлеккә! Җитмәсә, Татар Баганалысындагы төп йортларында калган уллары Илшат Чистайда эшли, көн саен диярлек кереп хәлләрен белешә. Гаиләләре белән килеп бакча эшләрен дә җир җимертеп эшләп китәләр икән.

Сагыну дигәннән, Тәнзилә апа үзе шушы ук районның Мөслим авылында туып-үскән. Ерак та түгел. «Менә Илдар абый гына ничек түзгән икән?» – дип шаяртып куйдым, аның Җирән ягыннан булуын белгәч. Олы Бәрәзә авылыннан икәнлеген ишеткәч. «Эш белән сагынырга вакыт та булмады бугай. Кайткалап йөрдек. Әле хәзер дә елга бер тапкыр кайтып, әти-әни каберләрен карап киләбез. Авылда якын туганнар калмады инде», – дип куйды моңа карыш Илдар абый. Сизелеп тора: Чистай аның икенче туган йорты кебек.

Казан педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң юллама белән җибәрәләр аны бу якларга. Башта Мөслимгә – укытучы, аннары Нарат-Елгага директор итеп. Ә Тәнзилә биология-химия укытучысы белгечлеге алырга җыенган җиреннән читтән торып укуга күчә дә, туган ягына кайтып, мәктәптә эшли башлый. Илдары Нарат-Елгада эшләгәндә, тормыш корып җибәрәләр. 1973 елда Илдар абыйны Татар Баганалысы мәктәбенә директор итеп күчерәләр дә, шунда төпләнеп калалар.

Баганалы юллары

Бу юлларны искә алу Тәнзилә апа белән Илдар абыйның төрледән-төрле уйларга әзерле кебек. Шулай булыр инде. Шатлыгы да, борчуы да шунда үткән бит.

– Мәктәп бик иске иде, – дип исләкләргә бирелеп китте Тәнзилә апа. Илдар абый сырхаулап торганга, күбрәк тыңлап утырды. – Бик авыр еллар булды. Алты авылдан 670 бала килеп укый иде. 30 кеше интернатта тора. Аның бинасын карау, тәртиптә тоту да безнең өстә булды. Берничә шартлар да юк иде. Җәй көне урманга барып, утын кистек. Мәктәп белән интернатның икесенә бергә 15 мич иде. Техничкалар мәктәптә куна-төнә ятты. Иртәнге сәгать 3тән яга башларлар иде. Хәзер кайчак шул вакытлар искә төшә дә, шатланып туя алмыйбыз: нинди куркыныч булса да, ут-күз тыкмады, Ходай саклады. Үзебез колхозның иске генә бер йортына килеп урнаштык. Озакламый улыбыз туды. Әни Мөслимдә ялгызы гына калган иде. Карашырга дип, аны чакырдык. Икенче, өченче балабызны да ул карап үстерешә. Башкача һич кенә булмый иде чөнки. Эш күп булып, мәктәп бинасыннан чыга алмый яткан көннәребез дә булды. Балалар өч сменада укыды. Җитмәсә, авыл яшьләре өчен кичке мәктәп тә эшли иде. Анда да укытабыз. Ул тагын агитатор булып йөрүләр. Фермалардан, кырлардан кайтып кермәдек. Укытучы да колхозчы белән берәттән көн күрде ул вакытта. Алар белән бергә суган, чөгендер үстердек.

Зөлфия Хәлиуллина

Илдар абый белән Тәнзилә апа рәхәтләнеп хәтер йомгагын сүттеләр.

Татар Баганалысында Нигъмәтҗановлардан бүләк булып, бакча гына түгел, мәктәп бинасы да калган.

– 1984 елда яңа мәктәп бинасы салдырдык, – дип дәвам итә сүзен Тәнзилә апа. – Янында 80 сутый бакчасы бар иде. Илдар көн-төн төзелеш эшләре белән чапты. Бакчада мин хуҗа булып йөрдем. Белгечлегем дә шул бит инде – биолог. Яшелчәләр, җиләк-җимешләр үстердек. Җәйге каникул вакытында бакча бер минутка да тынып тормады. Күп эшне укытучылар башкарды инде. Укучылар, бүлешеп, бер-ике атнага сибәргә генә киләләр иде. Уңыштан балалар үзләре файдаланды. Ул вакытта нишләптер авыл халкы мондый нигъмәтне үз бакчасында үстермәде. Бездән сатып алалар иде. Авыл советы белән планлаштырып, ата-ана комитетына раслатып, акчасына тәрәзә пәрдәләре, мәктәп өчен башка әйберләр алдык.

Районда безнең бакча гел алдынгы урында булды. Республика буенча да мактау грамоталары алган чаклар булды. Казандагы Авыл хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә тәҗрибәләр үткәрдек. Хезмәтемне дә бәяләделәр. Районда беренчеләрдән булып методист исемен бирделәр. Ел саен премиягә лаек булдык. Икебез дә Коммунистик хезмәт ударнигы, хезмәт ветераны исемнәре алдык. «Мәгърифәткә казанышлар өчен» билгесе белән бүләкләндек.

Кулыма аласым да килми

Остазлар белән бүгенге мәктәп турында да сөйләшеп алдык. Алар һич кенә дә уку-укыту эшләреннән, хәтта Татар Баганалысы мәктәбеннән дә аерылмаган әле, чөнки килене Гөлназ анда башлангыч сыйныфларны укыта.

– Элек ничектер аңлаешлырак булды, – ди Тәнзилә апа бу җәһәттән. – Балалар дәресләкләрдән укыр иделәр дә, ялт иттереп, имтиханнарны биреп куярлар иде. Хәзер ярдәмне күбрәк сорыйлар. Димәк, аңлап бетермиләр дигән сүз инде бу. Оныклар укыганда, мин аларга үзем дә аңлата идем. Чөнки хәзерге дәреслекләрне аңламыйм да, кулыма аласым да килми. Укырга кермәс борын имтиханга әзерләнә башлыйлар. Бернинди тынычлыклары да юк. Бер карасаң, бәхет эше генә инде ул имтихан.

> Хезмәт тәрбиясе бик көчле иде бит ул вакытта. Мәктәптә терлек-туарга кадәр асрадык. Шуңа укучылар укуны да булдырдылар, тормыш итәргә дә өйрәнеп үстеләр. Хәзерге балалар идән дә юа белмәскә мөмкин, ә ул вакытта идәнне ком белән ышкый-ышкый агарталар, ялтырап тора иде.

– Мин үзем дә 9 нчы сыйныфта укыганда җитештерү бригадасын җитәкләдем, – ди Тәнзилә апа. – Сыер карадык, бозаулар чистарттык. Беребез дә әзелеп төшмәде, юкка да чыкмадык. Хәзер дә хезмәт тәрбиясен кертергә кирәк. Шунсыз булмый. Ул заманда тәртипсез балалар да юк иде, милиция дә килмәде, гадәттән тыш хәлләр дә булмады. Әти-әниләр дә бер укытучылар яклы булды. Балаларны бергәләп тәрбияләдек. Ата-аналар колагына шунысын да әйтим әле: баланы якламаска кирәк. Ата-ана ягыннан яклау тапса, бала отыры тәртипсезләнә. Аның белән уртак тел табып, аңлата белергә, гаебен туры-туры әйтергә кирәк. Ачуланып та түгел, әрләп тә түгел. Яхшы сүзне берни дә алыштыра алмый.

Гадәттә, укытучының үз балаларына игътибары җитми, диләр. Аңлашыла ки, андый чаклар бу гаиләдә дә булгандыр. Әмма Илдар абый белән Тәнзилә апа әниләре ярдәме белән менә дигән балалар үстергәннәр. Уллары Илшат Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган. Агроном булып эшләгән. Хәзер бер предприятиедә директор вазыйфаларын башкара. Гөлнара мәктәпне дә, университетны да «5ле» билгеләренә генә тәмамлаган. Дәүләт Советында синхрон тәрҗемәче булып эшли. Гөлназның исә еш кына Бөтендөнья татар конгрессында очратырга була. Ул анда чит өлкәләрдә, илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән эшли. Әби белән бабайның бүген дүрт онык сөендерә. Бергә җыелсалар, гөр килеп туган телдә сөйләшәләр. Монысы да – Илдар абый белән Тәнзилә апаның зур өлеше кергән тәрбия нәтиҗәсе.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Кайсыгызның кулы җылы

Спортчы егет ярдәм көтә

Сиңа дигән сынау тормышыңның кайсы өлешендә көтеп торганын берәү дә белми. Балтач районының Бөрбаш авылында яшәүче Руслан Габдрахманов – армиягә барырга әзерләнеп йөрүче, сау-сәламәт, спортчы егет санаулы вакыт эчендә коляскага калыр дип ышана торган булмый.

– Күрше егете ул безнең, 25 яше дә тулмаган. Кечкенәдән бик актив, үзе бик тыңлаучан, акыллы бала булды. Аны шушы хәлдә күреп, йөрәгебез нык авырта, аның турында «Ватаным Татарстан»га язып, ярдәм сорый алмыйсызмы? – дип мөрәҗәгать итте авылдашлары Гөлнур һәм Равил Хәйруллиннар. – Әтиәнисе ярдәм сорап өйрәнмәгән, улларына моңа кадәр дә кыйммәтле дарулар алдылар, хастаханә юлларын күп таптадылар... Сулыш алу өчен кыйммәтле аппарат кирәк булгач та, сорарга кыймый йөрделәр, ярый әле, авыл җирлеге башлыгы район җитәкчелегеннән ярдәм оештыртты...

Русланның әнисе Лариса ханым сөйли: «Авыл мәктәбендә тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, Сабадагы аграр көллияттә укыды. Аны тәмамлап, Балтачка эшкә урнашкан иде. «Авырыйм», – дип зарланмады. Шул чакта аны хәрби комиссариатка медкомиссиягә чакырдылар...»

Барысы да әнә шуннан башлана. Табибләр, шикләнеп, Русланны Казанга тикшеренергә җибәрә. Хастаханә юлларында йөргәндә, әле чын диагноз куйганчы ук инде аның аяклары авырдан йөри башлый, мускуллары тартыша, «эшләми». Табибләр «болезнь двигательного нейрона» дигән бик җитди диагноз куя. Русланны әти-әнисе кайларга гына йөртми, файдасы булмый. Биш ел эчендә авыруы көчәя генә: аяклардан кулларга күчә, сулыш алуга, сөйләменә дә зыян килә. Башта авырлык белән йөргән аяклары бераздан бөтенләй тыңламый башлый.

– Мәскәүдә бер ай реабилитациядә булдык. Өч ай дәваланырга дигәннәр иде дә, акчага бәйле рәвештә туктадык. Анда безгә авыруның төп сәбәбе урман бете дигәннәр. Улыбызга урман бете кадалганын белмәдек тә, күрмәдек тә. «Без дәвалый алмыйбыз», – дип, берничә чит ил клиникасын тәкъдим иттеләр. Кытайдагы клиникада башкалардан үзгә алымнар тәкъдим иткәннәрен белгәч, күңел купты. Улыбызны ничек тә аякка бастырасы килә. Анда бер ай дәваланганнан соң, өч ай өйдә алар биргән дару-уләннәр белән дәвам итәсе була. Бер айлык дәвалану өчен 1 миллион 500 мең сум акча кирәк. Акча җыйналып бетүгә безгә чакыру киләчәк. Рәхмәт яусын, авылдашларыбыз барысы да хәл кадәренчә булыша, ике ел элек янгыннан соң да алар ярдәме белән яңа каралтылар корган идек. Кешедән ярдәм сорау җиңел түгел, әмма, хәлебезгә кереп, улыбызның да, безнең дә иң зур хыялыбызны тынга ашырырга ярдәм итүчеләр булса, без гомеребезгә рәхмәтле булыр идек, – ди Лариса.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Русланга ярдәм итәргә теләүчеләр өчен:
- **карта Юнион пэй.**
- **Газпромбанк счет номеры: 40817810563491257594. БИК 044525823. Сивенкова Лариса Васильевна (әнисе).**
- **Сбербанк картасы 89393961134 номерына бәйләнгән.**

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Мәңге яшә

Һәрбер эшнең нигезендә теләк ята. Менә мин – язучы. Мин синең мул, җитеш тормышта яшәвеңне телим. Шул вакытта син бераз тынычланып калырсың, рухи байлык турында да уйлый башларсың, бәлки, кулыңа китап алырсың, һәм ул китап, бәлки, минеке булыр. Минем һөнәр кешесе башка теләктә була алмый. Әгәр син ач-ялангач, бәхетсез икән – минем файдага түгел. Син үз хәлеңнән чыгу юлын эзлисең, шул хәстәр белән яшисең бит инде ул чагында. Андый вакытта кеше китап укып утырмый. Ә миңа синең китап укуың кирәк. Әгәр китап укыйсың икән – минекен мотлак алачаксың.

Җырчы һөнәре дә шундый инде. Ул да синең мул тормышта яшәвеңне, ару гына суммага билет алып, җәмәгатең белән җитәкләшеп концертка килүеңне тели. Концерт оештыра алмаганнары тамада булып йөри бит инде хәзер. Аларга да синең рәхәт яшәвең кирәк. Шул чагында гына син зурдан кубып юбилейлар, туйлар уздырачаксың, бәйрәмеңә тамада, җырчылар чакыра алачаксың.

Болары инде – табигате белән игелеккә омтыла торган һөнәрләр. Ләкин бик коточкыч булып тоелган, беркем дә яратмаган өлкәләр дә бар. Әйтик, салым хезмәте. Ниндидер бизнес ачасың, хөкүмәттән бер ярдәм дә күрмичә, аны җайга салырга тырышасың, тегесенә-монысына акча кирәк, ә ул җитеп бетми һәм нишләргә инде дип башыңны кашып торганда – шап! – салым хезмәте! – акча сорый. Сорамый, таләп итә. Әйтерсең, сиңа берәр төрле игелек күрсәткән, әйтерсең, кайда да булса ярдәм иткән. Юк. Төшенә дә кереп чыкмагансың. Ә акча кирәк булгач, килеп җиткән – таләп итә. Таләп итә, талап китә. Ләкин бу һөнәр кешеләре дә синең бай булуыңны тели. Бай һәм намуслы булуыңны. Шул вакытта син алар белән вакытында исәп-хисап ясап куя алачаксың.

Яки юл хәвефсезлеге хезмәте. Алар синең җитеш тормышта яшәп, машина алуыңны гына түгел, ә наличный акчаңны кесәңдә йөртерлек дәрәҗәдә булуыңны тели. Туктатты, сөйләштегез – кесәсенә тыктың. Ул да канәгать, син дә.

Сәүдә хезмәткәрләре дә сиңа гел изге теләк теләп тора. Аеруча, үзебезнең торгашларны куып чыгарганнан соң, базарларны басып алган Урта Азия, Кавказ, Памир сәүдәгәрләре. Алар – дини кардәшләребез, кеше күрмәгәндә: «Татарлар мәңге яшәсен һәм бай булсын!» – дип дога да кыла торганнардыр әле. Чөнки син бай булсаң, кәефең яхшы була. Кәефең яхшы икән: «Кайда бакма шушылар!» – дип канәгатьсезлек белдермисең. Канәгать булгач, җиләк-җимешне дә елмаеп кына сатып аласың. Бәясенә дә карап тормыйсың. Шулай булгач, алар да сиңа фәкать яхшылык кына тели.

Хәтта караклар да сиңа хәерхаһлы. Чөнки син бай булсаң гына таларлык, я урларлык малың була. Ә хәерче булсаң... Син хәтта каракларга да кирәкмисең. Хөкүмәткә генә кирәгең чыгарга мөмкин. Чөнки хәерчене талау ысулларын бары тик ул гына белә. Ә караклар... Әйткәндәй, соңгы арада караклар бөтенләй юкка чыкты бит. Юкка чыктылармы, каядыр күчеп беттеләрме шунда. Күргән юк. Телевизор да караган юк инде...

Ләкин шундый һөнәрләр бар... Әйтик, табут ясаучылар... Менә без: «Кеше гомере кыска», – дип зар елыйбыз бит инде. Алай түгел икән ул, үлемсезлек даруын әллә кайчан уйлап тапканнар икән. Бер галим инде, исемен белмим. Уйлап тапкан да бөтен дөньяга хәбәр салган. Даруын үзе эчәргә дә, кешегә бирергә дә өлгермәгән, шундук табут ясаучылар килеп җиткән. Үзен үтергәннәр, даруын түккәннәр, кәгазьләрен яндырганнар. Эшсез каласылары килмәгәндер инде.

Муллалар, поплар, дин әһелләре... Алар да сиңа бәхет теләми. Дөрес эшлиләр инде үзләренчә. Әгәр гел бәхет-шатлыкта гына яшәсәң, Алланы мәңге исеңә төшермисең бит син. Әгәр ул бай да, сәламәт тә, уңышлы да, бәхетле дә булса... Гомумән, тормышы бар яктан да җитеш булган кеше Ходайны бар дип тә белми. Ул үзен генә күрә башлый. Алланы искә төшерү өчен синең һич югында билең авыртырга тиеш. «Алла, билем...» – дип булса да йөрерсең шунда.

Яки врачлар. Син менә күз алдыңа гына китереп кара, көннәрнең берендә бөтен чирләр юкка чыкты ди. Беркем авырмый, беркем хастаханәгә бармый. Әлбәттә, бер ел буена врачлар моны сизмәскә мөмкин. Алар берни сизмичә, башын да күтәрмичә үзалдына сөйләнеп, мәңге язып бетереп булмый торган теге журналларын тутырып, берәр ел утырырга мөмкин. Ә аннан соң?! Эшсез калганлыкларын аңлагач, нәрсә булачак?! Болар инде койрыкларын бот арасына кыстырып, почмакларга сибелмәячәк. Болар татар теле укытучылары түгел. Болар тоташ иленә операция ясарга мөмкин. Аларга дару ясаучылар да кушылачак. Дарулардан килгән керем бетсә, әллә күпме миллионерлар пролетариатка әйләнергә мөмкин. Өстәвенә известь чыгаручылар да эшсез кала...

Боларның берсе дә сиңа сәламәтлек теләми инде. Байлык теләргә мөмкин. Аларга синең бай һәм сырхау булуың кирәк бит.

Сәламәтлекне сиңа мин телим. Язучы. Алай гына да түгел әле, мин синең мәңге яшәвеңне телим. Чөнки шушындый тозсыз язмаларны да укырга сәләтле булган кеше мәңге яшәүгә лаек.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе,

әнисе

кинәт вафат булу сәбәпле, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры Когогин Сергей Анатольевичның авыр кайгысын уртаклаша.

КАМАЛ ТЕАТРЫ АРТИСТЫ ЛӘЙСӘН ГАТАУЛЛИНА:

«ГЕРОЕҢНЫ ҮЗЕҢӘ ЯКЫНАЙТЫРГА ЯРАМЫЙ»

Театр дөньясына ул Тинчуринның Сәрвәре белән килеп керә, ә бераздан Галәүнең Саҗидәсен уйный. Хыялын ике елга «калдырып торып», соңыннан барыбер Казанга килгән яшь актриса Ләйсән ГАТАУЛЛИНАга укыган чакта ук олпат режиссерларның өметен акларга туры килә. Курку хисе, героиняң белән якынлык, сәхнәгә тугрылык һәм матурлык – без аның белән әнә шулар турында сөйләштек.

Ләйсән Гатауллинаның шәхси архивыннан

«Актриса булу теләге барыбер «бәреп чыкты»

:: Ләйсән, ни өчен нәкъ менә театр? Әйтик, нигә җырчы булмадың? Тавышың яхшы булганга сорыйм.

– Җырчы булырга хыялланмадым. Кечкенә чакта да җырларга ярата идем, әмма аны башкаларга, хәтта гаиләмә дә күрсәтмәскә тырыштым. Үзем генә калганда җырлый идем. Күңелем күбрәк чит ил музыкасына тартканга, әти-әнием аңламас дип уйладым. Икенчедән, булган сәләтемнән берникадәр оялганмындыр да инде. Аннан соң, театрда әйбәт җырлаган кебек тоелса да, профессиональ өлкәдә ул башкача яңгыраячак. Спектакльдә ялгыш кирәкле нотаны ала алмасаң да, җырны актер буларак уйнап бирергә тиеш буласың. Ләкин мин хәзер җырчы буларак та үсәргә тырышам, киләчәккә планнарым да бар.

:: Мәдәният институтына килгәнче, ике ел башка уку йортында укыгансың. Бу шулай ук сәләтеңне «яшерү»гә бәйлеме?

– 10–11 сыйныфларда уйланасың, эзләнәсең бит инде. Әти-әнинең: «Төплерәк һөнәр сайларга тырыш инде, кызым», – дигән киңәшенә дә колак саласың. Хәер, тәрҗемәче һөнәрен инглиз телен яратканга сайлаган идем. КФУның Алабугадагы филиалына укырга кердем. Ләкин соңыннан актриса булу теләге барыбер «бәреп чыкты».

:: Әти-әниең ни диде?

– Мин укырга керәсемне аларга әйтмәдем. 20 яшемдә мәктәп балалары белән рус әдәбиятыннан имтихан тапшырдым. Җәй көне Казанга киттем. «Сине алабыз, ләкин теге укуыңны ташлыйсың», – диделәр. Шунда әтигә шалтыраттым да: «Әти, мине алалар. Соңгы сүз синнән. Бар дисәң, барам, юк, дисәң, бармыйм», – дидем. Өйдә «җыелыш» уздырганнан соң, шалтыратып: «Ярар, бар инде, кызым», – диде ул. Ләкин мин Алабугадагы укуымны ташламадым, читтән торып уку бүлегенә күчтем. Шөкер, ике дипломым бар минем.

«Ә нишләп мин?»

:: Өченче курста укыганда, Фәрит Бикчәнтәев сине «Сүнгән йолдызлар»дагы Сәрвәр роленә билгеләде. Бу яңалыкны ничек кабул иттең?

– Беренче баш ролемне икенче курста, «Яшьләр сишәмбесе» кысасында Олег Кинҗәгулов куйган «Парковка» спектаклендә уйнадым. Сүзне шуннан башлыйм әле. Фәрит абый «Сүнгән йолдызлар» турында әйткәч, шатландым, дип әйтә алмыйм. Курыктым. Ә нишләп мин? Булдыра аламмы мин аны? Шикләндем.

:: Актер өчен «комфорт зонасы»ннан чыгу мөһим дип уйлыйсыңмы?

– Әлбәттә! Әйтик, минем башка театрдан килгән, бөтенләй таныш булмаган режиссер белән эшләп карыйсым килә. Әйе, бераз шүрләтә. Ләкин шул рәвешле син үзеңне сыныйсың бит.

:: Син баш рольләрне уйнаган ике капма-каршы спектакль – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» һәм «Ситса туй»ны алыйк. Профессиональ яктан кайсы күбрәк булышты сиңа?

– «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» – минем өчен бик катлаулы спектакль. Мин героинямны, ул кичергән кайгы-хәсрәтне, хисләрне беркайчан да аңлый алмаячакмын. Шуңа күрә һәр спектакльдән соң бик авыр. Тамашачыга нәрсәнедер биреп, әйтеп бетерә алмадым шикелле. Үзем өчен дә нидер ачмадым кебек. Ягъни спектакль саен үз өстеңдә эш дигән сүз.

Ә «Ситса туй» – комедия. Минем өчен беренче комедия. Аның үз кагыйдәләре, уйнау законнары бар. Шулай да, Алмаз абый белән безнең линиядә әлеге дә баягы драма көчлерәк.

:: Динә белән Саҗидәнең кайсы якынрак?

– Берсе дә якын түгел. Мин – аларга, алар миңа охшамаган, шуңа күрә уйнау кызык. Минемчә, персонажны үзеңә якынайтырга, охшатырга ярамый. Ул син түгел һәм була да алмый. Аны яратырга, аңларга тырышырга гына кирәк.

«Йөрәк кушканча яшисем килә»

:: Артист өчен тышкы кыяфәт мөһимме?

– Артист матур булырга тиеш, дип әйтәләр инде. Ләкин кешене тышкы кыяфәт кенә матур итми. Кеше белеме, эчке дөньясы белән матур булырга тиеш. Бигрәк тә артист кеше.

> **«Сәхнә бит наданлыкны да, начарлыкны да – барын да күрсәтә».**

:: Эчке дөньяны баетырга вакытың каламы?

– Бүген студентларым бар – мин шуның белән бәхетле (Ләйсән Фәрит Бикчәнтәевнең яңа курсын укыта. – **Авт.**) Алар белән үзем дә студент мин, укудан, белем эстәүдән туктаган юк. Болай да вакыт табарга була.

:: Яшереп торасы юк: бүген кешене, нинди дер зур хыялларга караганда, акча күбрәк кызыксындыра. Бу җәһәттән син үз эшеңнән канәгатьме?

– Әлбәттә, әйбәт яшисе килә. Минемчә, ир-атларга безгә караганда авыррактыр. Дөрес, минем дә акча ягыннан ир-атка бәйле буласым килми. Ләкин бу зарлану түгел. Нәрсә дә булса уйлап табарга була.

:: Яңа гына арабыздан киткән Наилә апа Гәрәеваның «уйнаудан туктамыйча китеп барсам да, үкенмәс идем» дигәне бар иде. Синең театрга тугрылык, гомереңне бу өлкәгә багышлау турында уйланганың бармы?

– Соңгы сулышыма кадәр театрда уйнармын, дип кистереп әйтә алмыйм. Кеше үзе дә, аның тормышка карашы да үзгәрүчән бит ул. Минем бары тик йөрәгемне тыңларга өйрәнәсем, күңелем кушканча яшисем килә.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Хәтер

БӘХЕТЛЕ БУЛЫГЫЗ!

Разил Вәлиев, үлем белән якага-яка килеп көрәшеп, бакыйлыкка китеп барды. Шуңа күрә, авыруы яман икәнен белеп тә, үләсенә ышанмадым. Бер көнне кеше ышанмаслык хәл булды. Иртәнге намаз вакытында теләкләр теләп, Ходайдан: «Дустым Разил Исмәгыйль улына исәнлек бир...» – дип сорый гына башлаган идем, кемдер бик ачык итеп: «Хәзер соң инде», – диде. Өйдә хатын белән икебез генә, бүтән берәү дә юк. Тәмам каушап калдым. Ә тавыш аермачык иде.

Шуннан соң, ярты сәгать чамасы вакыт узды микән, бер дустым шалтырата. «Разилебез китеп барды бит», – ди. Ул көнне кулдан эш төште, гомумән, атна буе аңгы-миңге йөрдем.

Разил Вәлиев белән 1967 елны таныштык, мин – КДУ, ул Мәскәүдә Горький исемендәге әдәбият институты шәкерте иде. Ә аның якташы, дусты Рифкать Муллин белән тулай торакта бер бүлмәдә яшәдек. Разил Казанга кайткан саен безнең янга керми калмады. Әлбәттә, аның белән шундук ахирәт дусларга әйләнмәдек. Кешегә бик озак ияләшүен, ә дуслашса, бу дуслыкның гомергә сузылуын әйткәне бар иде. Без аның белән бер-беребезне югалтмыйча 55 ел яшәгәнбез икән, димәк, дуслыгыбыз вакыт сынавын узган. Язганнарым «арыслан күләгәсендә тиен туенган» булып аңлашылмасын, ул миңа остаз, фикердәш булды. Туфан ага әйтмешли, «җеннәребез килешкән», күрәсең.

Разил авырый башлагач, аның белән телефон аша гел язышып тордык. Хәлләре мөшкел булса да зарланмады ул. Авыру турында сүз кузгатсам да: «Әйдә, ул темага сөйләшмик әле, Казан хәлләре турында яз, газетагызда чыккан мәкаләләреңне җибәргәләп тор», – ди иде. Европада сәламәтлек эзләп йөрде ул. Австрия башкаласы Венага зур өметләр белән китте. «Минем авырудан дәвалаучы бердәнбер клиниканы шунда таптык», – дип куангандай иткән иде. Тик Европа аңа ярдәм итә алмады. Безнең язышулар өметле һәм өметсез сүзләр белән аралашып барды. Берсендә аңа: «Киләсе елда миңа җитмеш биш тула, моңа хәтле юбилей белән бер-беребезне котлаша килдек, традицияне бозмыйк! Мине котлар өчен сүзләр эзли тор, тиздән Казанга кайтырга тырыш!» – дип язган идем. Ике сүздән торган җавабы шундук килеп җитте: «Тырышырга тырышырмын».

Тырышмады түгел Разил дус, хәл белешкән саен «Чыдасаң, түзәрлек», «Зарланасы килми. Үз күңелемне үзем күреп яшәргә тырышам...» кебек сүзләр яза иде. Тик бер көнне язганы сискәндерде. «Яшибез. Ә ни өчен? Кайчакта шул турыда уйлап куям. Синең фикер ничек?» – дигән иде ул. Бераз үпкәләдем Разил дуска. «Ничек инде, ни өчен? Туганнар, дуслар куансын өчен яшибез. Менә бүген Рашат Низамины җирләдек, күпме кеше кара кайгыга батты. Син эгоист булма, Разил туган! Синнән кечкенә генә бер хәбәр килсә дә, күңел шатлана», – дидем. Кәефне төшерерлек сүзләрне бүтән язмады Разил.

Төрле бәйрәмнәр, туган көннәр белән тәбрик итүләр безнең өчен гадәти хәл иде. Тик менә Разил үзенә исәнлек, бәхет теләгәнне өнәп бетерми иде. «Мин генә исән-сау, бәхетле яшәп, дусларым, туганнарым, милләтем бәхетле булмаса, миңа яшәүнең ни кызыгы бар?» – дип әйтә торган иде. Бу сүзләр – аның тормыш кредосы. Кредо – аерым бер шәхеснең яшәешкә үз мөнәсәбәте, нәрсәгә дә булса ихануы, хәтта җәмгыятьтә төпләп урнашкан кайбер фикерләргә каршы килеп, үзенә аерым бер сукмак салуы, үз яшәү рәвеше. Разил халкы өчен яшәде, дисәм, бер дә арттыру булмас. Үләренә санаулы көннәр калганда ул: «Бәхетле булыгыз!» – дип язды. Бу ике сүз нәкъ менә дусларына, туганнарына, газиз халкына соңгы теләк, соңгы үтенеч, нинди дер чакыру, фатиха кебек иде.

> **Сүз дә юк, тарихта күп вакыйгалар, аерым шәхесләр дә вакыт узу белән онытыла инде ул. Ә хәтер озайту – исәннәр эше. Без ил, милләт язмышы тарихында эз калдырган шәхесләребез турында әледән-әле хәтер яңартып торырга тиеш.**

Разил чын мәгънәсендә милләт улы иде. Аның «Яшисе килә» дигән беренче күләмле әсәрен, әсәрдәге төп герой – Рифкать Миргазизов турында Разилнең сокланып сөйләп йөрүләрен бүген дә хәтерлим. Рифкать – аның якташы. Армиядә хезмәт иткәндә хәрби өйрәнүләр вакытында бер солдат граната алкасын тартып чыгара да, нишләргә белми, куркып-аптырап кала. Ә тирә-ягында – командирлары, хезмәттәшләре, аларның язмышын мизгел хәл итә. Менә шул вакытта Рифкать гранатаны гәүдәсе белән каплый һәм һәлак була. Мин ни өчен бу әсәрне телгә алдым? Разил үзенең якташы, Рифкать Миргазизовның батырлыкка ничек әзерләнүе турында язганда, иң беренче чиратта аның татар егете булуына басым ясаган иде. Ул чакта мин телевидениедә мөхәррир идем һәм Разилне тапшыруга чакырып, үзебезчә бер «батырлык дәресе» уздырдык.

Җәмгыятьтә зур үзгәрешләр барган туксанынчы елларда ул Татарстанга мөстәкыйльлек таләп итүчеләрнең алгы сафында иде. Дөрес, мәйданга чыгып: «Азатлык!» – дип кычкырып йөрмәде, ачлык игълан итмәде. Аңа: «Син дә ачлык игълан итмисеңме соң?» – дип төрттергәнем дә булды. Разил: «Ач торган кеше хәлсез була, ә көрәшер өчен көч кирәк», – дип җавап биргән иде. Ул депутат буларак, дәүләтчелекнең законлы нигезен эшләүдә катнашты. Мөстәкыйльлеккә омтылган Татарстанның Бәйсезлек турында декларациясен кабул итүдә, Конституциясен язуда да өлеше шактый булды Разилнең. Әле бит ил тормышында вәкаләтләребезне арттыру, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итү буенча күпме законнар кабул ителде, Төп Законга өстәмәләр кертелде. Әлеге хокукый нормалар, нигездә, Разил Вәлиев җитәкләгән «Милли комитет»та эшләнде. Ул җитәкләгән комитетны үзебезчә кыскартып, «милли комитет» дип кенә атап йөртә башладык без. Кайбер хокукларыбыз

shayantv.ru

кысыла, чикләнә башлагач та, ул төшенкелеккә бирелмәскә тырышты: «Хәрби тактикада «сугыша-сугыша чигенү» дигән төшенчә бар», – дип, күңелне күтәрергә тырыша иде һәм үзе сугыша-сугыша яшәде дә.

Ни кызганыч, аяусыз үлем аны җиңде. Мин аңа: «Разил туган, син – Ташлык авылы егете, таш кебек нык, теләсә нинди авыруларны җиңәчәксең», – дигәнрәк сүзләр язып, аның күңелен күтәрергә тырыштым. Разил бер көн дәшми торды да, аннан соң: «Риман дускай, яхшы сүзләрең өчен рәхмәт, тик авыру миннән ныграк булырга охшаган», – дип язды. Ә соңгы язуында, әйткәнемчә, безгә бәхет теләде. Никадәр сәер тоелмасын, мин үземне бәхетле саныйм. Разил исән булса, аңа да шулай дияр идем. «Татарда синдәй егет булу – үзе үк бәхет», – дияр идем. Хастаханәдә үлем белән тартышып яткан дустыма: «Син тугансың – безгә сан булган», – дип тә язган идем. Ул: «Үсеп җиткәч, шагыйрь булырсың син», – дип төрттергән иде.

Инде менә дустыбызның вафатыннан соң 40 көн узды. Ни өчендер бер генә мәртәбә дә төшемә кермәде Разил. Дин әһелләре: «Җаны тынычлык тапкан», – диделәр. Амин, шулай булсын! Ә безгә тынычланырга ярамый. Дустыбыз башкарган эшләрне дәвам иттерсәк, халык хәтерендә Разил Исмәгыйль улының гомерен озайту булыр иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

УКУЧЫ СҮЗЕ

Чишмә башы

Бер эсседән качып,
Бер суыктан,
Кыргыйлыктан җаннар көйгәндер.
Тау астыннан чишмә тибеп чыккан,
Бер яхшылык булсын, дигәндер.

Тау итәген ярып чишмә типкән,
Салкын гына суы – саф көмеш.
Челтер-челтер итеп агып киткән,
Дөнья буйлап киткән саф килеш.

Ярларына яран гөлләр үскән,
Юлаучылар ятып су эчкән,
Төннәрендә ай шәүләсе төшкән,
Иң кадерле нигъмәт – су икән.

Анда килеп намаз укыганнар,
Мосафирлар дога кылганнар.
Чишмә башы – изге урын, диеп,
Тәсбих әйтеп торган урманнар.

Гомер бакый дигән гөлбакчада
Сандугачлы таңнар яктыра.
Ага-ага суы болганса да,
Чишмә башы һаман саф тора.

Гамил АФЗАЛ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Өстәл бизәге

Элек татар өйләрен җырлап утыручы самавырдан башка күз алдына китереп булмаган. Безнең әбиләребез, әниләребез шатлыгын да, кайгысын да самавыр янында якыннары белән бүлешкән, тирләп-пешеп кайнар чәй эчәргә яраткан. Чәй эчү гаиләне бер-берсенә якынайткан, берләштергән. Кызганыч, татар халкының бу матур йолалары хәзер артта калып бара. Гаиләләрдә күмер чыжлаткан самавырлар кайнамый, аларны электр самавырлары, газ чәйнекләре алыштырды.

Яшел Үзән районы Мулла Иле мәдәният йортында, гореф-гадәтләрне, йолаларны кире кайтару максатыннан, «Җиз самавыр җырлап тора өстәлемнең түрендә» дип исемләнгән очрашу кичәсе булып узды. Шушы чарада самавырның тарихы, татар халкының чәй эчү традицияләре, чәйнең төрләре турында әңгәмә оештырылды. Килгән кунаклар самавырга, чәй эчүгә багышланган шигырьләр сөйләделәр, үзләренең хатирәләре белән уртаклаштылар. Бәйрәм самавырдан хуш исле үләннәр – мәтрүшкә, лимон бөтнеге, кырлыган (хан үләне), юкә чәчәге кушып ясалган кайнар чәй эчү белән төгәлләнде.

Самавырдан чәй эчүне, күңел бәйрәме, дияр идем мин. Мондый чәй табыны янындагы очрашулар кешеләрне дуслаштырып кына калмый, берләштереп, бергә туплый да.

Рәзинә СӘЙФЕТДИНОВА.
Яшел Үзән, Мулла Иле

Сүзләр күп җыелган

Олы Карамалы авылының 100 еллык тарихы булган урта мәктәбен 1978 елда 78 укучы тәмамладык. 10 авылдан җыелып укыдык. Моннан 25 ел элек, укуны тәмамлаганга 20 ел үткәч, очрашу оештырган идек. Ул вакытта мәктәбебез тора иде әле. Ни кызганыч, хәзер ул бина юк инде. Егерме еллыктан соң башка очрашу оештыру насыйп булмады.

Ничек тә очрашырга кирәк дип, өч ел элек тә уйлый башлаган идем. 78 укучының 14е бакыйлыкка күчтеләр, урыннары җәннәттә булсын! Былтыргы язда тагын бер сыйныфташ кызыбызның арабыздан китүен ишеткәч, исән чакта очрашырга кирәк дип, бу эшне башларга булдым.

Берничә кыз очрашып, көнен, вакытын билгеләдек тә, Рәйсә, Галиябану белән оештыру эшләрен башлап җибәрдек. Чыгарылыш альбомын алып, һәрберсен барлап, телефон номерларын эзләүләр, сөйләшүләр китте. Классташлар төркемен ачтык. Менә шунда китте сөйләшү-аралашу. Шундый сагынышканбыз икән.

Иң дулкынландырганы 8 июльдә «Мандарин» кафесында булды. Ишектән килеп кергәч, кайберләребезне танымый да торабыз. Һәр классташка значок тапшырып, Госман белән Исхак кызларны роза чәчәкләре белән каршы алдылар. Дамир белән Роберт, Рәйсә белән икебезгә, оештыручыларга рәхмәт йөзеннән дип, зур чәчәк бәйләме бүләк иттеләр. Шулай хөрмәт итеп, эшебезне бәяләгәннәре өчен, үзләренә рәхмәт.

78 укучыдан очрашуга 44ебез килде. Укытучыларыбыз хөрмәткә лаек, бик тә намуслы, үз эшләренең осталары иде. Бүген рус теле һәм әдәбияты укытучысы Мөршидә апа гына исәнсау. 29 сентябрьдә 75 яшьлек юбилее булды. Аңа исәнлек-саулык, тынычлык, балаларының-оныкларының игелекләрен күреп, хәерле гомер кичерүен телибез. Башка укытучыларыбыз арабызда юк, урыннары җәннәт түрләрендә булсын.

Мөршидә апаның ире Рафик абый без укыган елларда мәктәп директоры булды. Физика белән астрономия фәннәрен укытты. Дәресләрне бик кызыклы алып бара иде. Һәрвакыт елмаеп сөйләште. Очрашуда аны да искә алдык. Рафик абый Фирдәвес белән Кәсимәне «ярата», һаман саен бастырып нәрсә дә булса сорый, сөйләтә иде, диештек.

Төрле сәбәпләр аркасында очрашуга кайта алмаучылар да булды. Алар белән аралашып торабыз. Бер-беребез турында күбрәк беләсе килә бит. Мәктәптә укыганда да өч класс бергә дус-тату яшәдек. Хәзер барыбыз да олыгаябыз. Еллар үткән саен яшь чакны күбрәк искә аласың икән.

Очрашуны озак көтсәк тә, вакыт тиз үтеп китте. Таралышасы килмәде, сөйләшәсе сүзләр күп җыелган иде. Аллаһыга мең шөкер, уйлаган эшне башкарып чыктык. Исән-сау булып, тагын очрашулар насыйп булсын.

Фирдәвес МИФТАХОВА.
Кама Тамагы, Олы Карамалы

КАЛФАКЛЫ САНДУГАЧ

Күренекле композиторыбыз Сара апа Садыйкова татар халкына 300дән артык җыр бүләк итеп калдырды. «Беренче мәхәббәт», «Җидегән чишмә», «Көтәм сине», «Солдатым», «Әнкәй», «Татарстан – минем республикам», «Яшьлегем эзләре» – халык бүгенгә кадәр яратып башкара торган җырларның кайберләре генә.

Казанның Актерлар йортында күренекле композиторыбызның туган көне уңаеннан үткәрелгән концертта Миңгол Галиев, Рөстәм Асаев, Рөстәм Гыйльфанов, Айдар Габдинов, Гөлнара Байназарова башкаруында без бу мәңгелек көйләрне кабат ишеттек. Якташлары – апаслылар, Сара апага багышлап, шигырьләр укыдылар. Тамашачылар аның кызы Әлфия Айдарскаяны аягүрә алкышлады.

Равилә МӨБАРӘКШИНА

Хатирәләр

Сандык

Гөнаһлар җыеп картаелды, ничек үтәрсең сират күперләрен, дип көрсенеп куяр иде ак әбием. Үзе бер гөнаһсыз булгандыр инде ул, җанашым.

Аның кече яктагы карават янында сакланган «үлемтек сандыгы»ннан шулкадәр шүрли идем мин. Нафталин исләре чыгарып торган сандыкны ачып, кайбер көнне әби шундагы чүпрәк-чапракны, сөлге-тастымалны, носки-оекны тегеләй әйләндереп, болай әйләндереп карый. Үзе миңа сөйли: «Үлемтеккә унбиш метр ак бәз материя әзерләдем. Монысы тугыз метр шадра – анысы гүргә иңдерү өчен кирәк. Менә монысы ләхет алган кешегә, монысы мәет югаңнарга, монысы...» Мин ул әйберләрдән, әби сөйләгәннәрдән шикләнсәм дә, кич белән күземне дә йомарга куркып ятачагымны белсәм дә, кызыксынуым өстен чыга иде. Әбине йөдәтеп, әллә нинди сораулар бирә идем. Ул сабыр гына, әллә ничә кат аңлата. Иплэп-җайлап, чыгарган әйберләрен яңадан сандыкка тутырып куя. Аннары бәби итәкле алъяпкыч кесәсен капшап, берәр балага бирергә дип салып куйган кәнфитен тоттыра. Әбиләр тәрбиясе нык иде шул элек.

Зирәклек

Әле уртак тормышның башы гына булган. Шулай бервакыт бер үк көнне әнине дә, әбине дә төрле күршеләр каз өмәсенә чакырган. Өйдә ике яшь бала. Күрше карчыгы әбине алырга кергәч, әни бер баланы аңа ияртеп, икенчесен үзе белән алып китәргә исәпләп, киендерергә тотынган. Әмма әбинең бу юлы бала ияртәсе килмәгән. Ул чыгып китәргә җыенган арада әти кайтып кергән. «Нишләп син дә бармыйсың? Син дә чакырулы бит», – дигән ул, әнигә карап. Эшнең нидә икәнлегенә төшенгәч, әбигә – апаны, әнигә абыйны җитәкләтеп, икесен ике йортка өмәгә җибәргән әти. Килен-каенана тавышланмый, үпкәләшми, риза булып чыгып киткәннәр өйдән. Әтинең зирәклеге аларның дус-тату торуларына бик зур этәргеч булган. Әти үлгәннән соң, әбинең: «Төшке ашка кайтмаса да юксына идем. Ничек түзәрмен?» – дип елаганы күңелне һаман да телеп тора. Әтидән калып, тагын 12 ел яшәде әле әбиебез.

Игелек

Безнең авыл Чаллы – Әлмәт трассасыннан ерак түгел. Юлда төрле хәлләр булып тора.

Бервакыт шулай улап-улап буран уйнаган, җил тәннән бөтен җылыны ала торган, күз ачкысыз буранлы көн иде. Юлда ничәмә километрга сузылган «бөке» оешкан. Инде көн кичкә авышып килә, буранның туктарга исәбе юк. Машиналар кузгала да алмый торалар. Әти кабаланып кайтып керде. Әни дә, әби дә өйдә иде. «Термоска баллап кайнар чәй ясагыз, коймак булса да пешереп алыгыз, юлдагы автобусларда балалар да бар, шуларга алып менәм», – дип, әти күз ачкысыз буранда коймак һәм чәй тутырган сумканы күтәреп чыгып китте. Ул арада булган ризыкларын ашатып, яшүсмер балалары булган ике гаиләне ияртеп тә төшкән. Алар бездә куна калды ул көнне. Үзе термосына, банкаларга күбрәк кайнар чәй тутырып, коймаклар алып, юлга яңадан менеп китте. Машинадан машинага күчеп, бу юлы ул бездән бер өч километр ераклыктагы Түбән Пәнәче авылына кадәр барган. Бик туңып, күшегеп кайтып кергән иде.

Яхшылык җирдә ятмый, ул үзеңә яхшылык булып кайта. Берничә елдан соң бер егетнең, онытмыйча, әти-әнигә рәхмәт әйтер өчен безгә килеп киткәнен хәтерлим.

Тот каракны!

Җәй көзгә авышып бара. Уңыш өлгергән вакыт. Бер мәлне авыл яшьләре, җыелып, клуб янында утырабыз. Диңгез төбе кебек куе зәңгәр кич. Йолдызлар, котырткандай, шаярып, күз кыса. Ябык клуб тәрәзәсендә агач шәүләләре генә уйный. Берзаман ничектер күңелсез булып китте. Шунда кемдер: «Әйдәгез Федотка көнбагыш урларга барабыз», – димәсенме.

Карман башыннан санасаң, Федотово дигән урыс авылы бер километр чамасыдыр. Су аркылы күпер чыгасы гына бар инде. Ул көнбагыш үстереп, көнбагыш сату белән танылган авыл иде. Бик шатланып, шунда юл алдык. Бакча тутырып, көнбагыш чәчкәннәр. Бер башыннан кереп, көнбагышларга үрелүебез булды... Аһ, беттек... Ул арада этләр ләңләң килә, урысчалатып бер хатын кычкыра да башлады. Без тораташ булып катып калдык. «Чүгәләгез!» – диде кайсыдыр. Ул да булмады, тын һаваны ярып, мылтыктан атып җибәрделәр. Авылга кайтып җиткәнче, өнне-көнне белми чаптык. Кемдер өзәргә өлгергән бер баш көнбагыштан төшләрне чүпли-чүпли, үзебезне тынычландырдык ул көнне.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

ШОДА АВЫЛЫНДА КУНАКТА

Куныр авылы җирлегенең «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе, Шода авылы кызы Фәйрүзә Зәкиева каз өмәсенә дәште.

Каз өмәсе

Зәкиевләр нәселе – авыл горурлыгы. Әтисе Гыйльмулла Дәүләтшин 30 ел авыл советы рәисе булып эшләгән, авылның яңаруы, төзекләнүе өчен янып-көеп яшәгән. 5 баланың дүртесе шушында төпләнгән. Фоат абыйсы пилорама тота, Азат энесе «Балкыш» авыл хуҗалыгы кооперативы төзеп, гаиләсе белән шунда хезмәт куя. Төпчекләре Илшат, төп нигездә калып, бригадир, ферма мөдире, зоотехник булып эшләп, «Якты юл» хуҗалыгын үстерә. Фәйрүзә 43 ел балалар бакчасын җитәкли.

Тукта, сүзем каз өмәсе турында иде бит! Әлбәттә, мондый зур, күркәм чараны ялгызың башкару мөмкин түгел. Мондый туганнар, бердәм гаилә, авыл активистлары, Илзия Нәҗипова, Гөлшат Шәрәфетдинова кебек дуслар янәшәдә булганда, әлбәттә инде, зур эшләр кубарырга була. Кунырлылар белән шодалылар гомер-гомергә дус-тату яши, өмә шушы ике авылны тагын да берләштерде. Икесеннән дә каз йолкучылар да, концерт номерлары да, күргәзмәләр дә булды.

Капка киереп ачылган. Йорт хуҗасының нәни онытлары безне милли киемнәрдән ипи-тоз белән каршы алдылар. Колмак чүпрәсе белән пешкән ул ипинең тәме әле дә авызда! Гадәти авыл өе, кое, мунча, баз өсте. Өстәлдә зур самавыр җырлый. Хуҗабикә каз маенда пешкән кайнар коймагын өстәлгә тезә тора, ул авызда эри тора.

Казларны, аякларын бәйләп, кыйблага каратып тезделәр. Йолкырга каты булмасын дип, суючының артына типтеләр. Казлар суелып беткәч, хәрам йонын алып, баш-аяк, канатларын кисеп (хуҗабикә канатларны санап алып, яшереп куя, югалса, кул китә), мунчага йолкырга кертәбез. Беренче суелганы иң ахырдан кертелә. Идәндә зур җәймәгә башта йоны, аннан мамыгы төшерелә. Йон-мамыкны сүрүгә бары ирле хатыннар гына тутыра. Үсмерләр баш, тәпи чистарта.

Эч маен, дирбияләрен алгач, казларны инешкә алып төшеп, агымсуда юабыз. Авылда гармунчыларның дәртле җырлары яңгырый, су буенда җырлап-биеп җылынып алалар. Бала-чага юлга каурый чәчә, аларга конфет өләшәләр.

Казның бер генә әгъзасы да ташланмый. Орчык белән әйләндереп чистартып, карда таптап юылган эчәктән вак бәлеш, бәрәңге шулпасы пешерәләр. Бәлеш эченә бәрәңге, борай, бодай ярмасы тәмле була. Озын кышкы кичләрдә балалар каурый сыдыра, аның мамыгы мендәр-ястыкны аеруча йомшак итә. Очыннан май канаты үрәләр. Быел бу гаилә 40 баш бәбкәне исән-имин үстергән.

Гүзәллек дөньясы

Шодага килеп, Мирхәйдәр Фәйзи музеен күрми китү гөнаһ булыр иде. Шода мулласы, драматургның абыйсы Сәетгәрәй Фәйзуллинның ике катлы агач йорты бүген дә тарихи ядкарьләрне кадерләп саклый. Чү! Галиябану белән Хәлил җырлый түгелме? Аны Фәйрүзә ханым белән Фоят әфәнде башкара икән. Яшь егет Мирхәйдәр авыл сылуы Сәгъдәтбануга гашыйк була, тик кызның сөйгән егете барлыгын белгәч, араларына кермәскә уйлый. Музейда гаҗәп бай, искиткеч үзенчәлекле экспонатлар тупланган. Күңелдәге тәэсирләр белән әкрен генә мәдәният йортына юнәләбез. Иң элек Гөлшат Шәрәфетдинова күргәзмәсе янына киләбез. Андагы гүзәллек! Энә тоткан куллары чын могҗиза тудырган. Кызыксынып, мамык мендәр тышындагы бизәкләрне каян алуын сорыйм. «Вәгазь китабының почмагында күренер-күренмәс бизәк бар иде, мин шуны зурайтып ясадым. Әгәр бизәктә бушлык килеп чыкса, аны үзем уйлап чыгарган орнамент белән тулыландырам. Гомумән, мин бөтен җирдә бизәк күрәм, аны тизрәк кәгазьгә төшерергә я хәтергә салып куярга тырышам. Менә сезнең күлмәктәге бизәкләр дә берзаман минем чигешләрдә урын алачак!» – ди Гөлшат ханым.Ниләр генә юк биредә: намазлыклар, сөлгеләр, мендәр, өстәл япмалары. Мамадыш кунагы Зөмәрия ханым каз мамыгы тутырган затлы чигүле пар мендәрне сатып та алды. Гөлшат ханым күп күргәзмәләрдә җиңү яулаган.

Гөлшат ханым чиккән сөлгеләр безне генә түгел, Казанда «Милли сөлгеләр» конкурсында мәртәбәле жюрины да таң калдырган. Ул әле авыл апаларын һәм балаларын да тегү-чигүгә өйрәтә икән.

Җылы юрган

Авыл халкын, кунакларны иң нык кызыксындырганы – каз мамыгыннан евроюрган сырып күрсәтү. Ул мастер-класс дип атала инде. Гөлсем ханым Миңлебаева 90 нчы елларда мондый юрганнарны тегеп сатып, гаилә бюджетын шактый ныгытуын сөйләде. Үзенең 35 ел элек сырган юрганы, көн дә ябынып ятсалар да, әле өр-яңа икән. Сүрүне, 20 см тирәсе ара калдырып, тигез итеп сырып чыкканнар. Һәр арага учлап каз мамыгы алып, шуны әкрен-әкрен кулдан ычкындырып, полоса буйлап таратып чыгасың, аннан икенчесен, өченчесен. Тутырып бетергәч, авызын ике яклап тегеп куясың. Бер евроюрганга 1 кг каз мамыгы кирәк. Үрдәк йоны белән дә эшләргә була. Ул нәкъ каз мамыгы төсле икән. Бу эшне Халисә, Айгөл һәм Гөлсем ханым башкарды. Бәби арбасына кую өчен тегелгәне тагын да үзенчәлекле. Аны озынча итеп сырганнар. Яртысын астына җәясең дә калганын өстенә әйләндереп ябасың. Сабый мәмрәп җылыда йоклый. Тагын шунысы бар: яңа тутырылган мендәр, сырылган юрганнарны, исе бетсен өчен, бер ел киптерергә, җилләтергә кирәк. Шуннан исе дә бетә, кабарып та китә. Килгән кунаклар осталарга юрган сырырга заказларны бирде инде.

Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА.
Балтач

И туган тел, и матур тел...

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ТАҖИК

Казан

ИКЕ ВАТАНЫБЫЗ БАР

Бу юлы без таҗик гаиләсе белән таныштык. Йорт хуҗасы Мәҗит Убойдуллаев, әңгәмәгә керешкәнче үк: «Татарстан ул – безнең икенче туган йортыбыз», – дигән иде. Болай дип әйтүе тикмәгә түгел. Беренчедән, алар Казанда инде күптән, 2006 елдан бирле яшиләр. Икенчедән, Мәҗит Насриевич башкалабыз шартларында, үзе озак еллар хыялланганча, фән кешесе булып киткән. Өченчедән, дин дә бер үк, телләр дә охшаш, татарлар янәшәсендә бик тиз үз кеше булып китәргә була. Моның өчен, әлбәттә инде, үзеңә дә тырышырга туры килә. Димәк, Убойдуллаевлар сер бирмәгәннәр.

Олы кызы Сәрвәрхон белән.

Рәхмәттән башка сүз юк

Яшерен-батырын түгел, Таҗикстаннан килгән мигрантлар турында сүз чыкса, күп кеше аларны я базарда сатучы, я төзелештә эшләүче итеп кенә күрә. Техник фәннәр докторы, Казан технологик фәнни-тикшеренү институтының «Конструкцияләү нигезләре һәм гамәли механика» кафедрасы профессоры Мәҗит Убойдуллаев исә бу хорафатларны төбе-тамыры белән юкка чыгара. Ул үз тырышлыгы белән зур казанышларга ирешә. Гаиләсендә дә тәртип. Балалары, оныклары туган телдә сөйләшә. Гореф-гадәтләрне саклап яшиләр. Ирешкән уңышлары күбрәк туган җирне дә, торган җирне дә аңлап яшәгәнгә бәйледер, мөгаен.

– Без Россиядә күптән инде. Берара Уфада яшәп алган идек. Анда да безне яхшы кабул иттеләр.

Әмма Татарстанда үзебезне әйбәтрәк хис итәбез. Монда башка милләт кешеләренә дә, чит илләрдән килгәннәргә дә игътибар бик зур. Халыклар дуслыгы йорты – безнең кебекләр өчен үзе бер җылы оя кебек.

Һәр милләтнең мәнфәгатьләрен кайгырту, телне, гореф-гадәтләрне саклап калу өчен әйтеп бетермәслек шартлар тудырылган. Балаларны туган телгә өйрәтү өчен якшәмбе мәктәпләре эшләп тора. Нинди генә чаралар, бәйрәмнәр үткәрелми. Үзебез дә еш булабыз. Иң мөһиме, авыр хәлдә калган милләттәшләребезгә ярдәм итәргә тырышабыз, проблемалар килеп туса, бергәләп хәл итәбез. Чит җирләрдә ялгыз калу бик авыр булыр иде. Бу җәһәттән Татарстан Хөкүмәтенә рәхмәттән башка сүзебез юк.

Исфара балалары

Убойдуллаевлар гаиләсендә туып-үскән балалар нәкъ менә Казанда олы юлга аяк басканнар: һөнәрле дә булганнар, тормыш та корганнар. Әти-әниләре белән йорт та төзеп чыкканнар. Хәзер инде бу йорт – алар өчен төп нигез, бала-чага тавышыннан шау-гөр килеп тора. Оныклар сигезәү. Өлкән кызлары Сәрвәрхон – өч бала, уллары Оразхон – ике, уртанчы кызлары Зевархон – бер, кече кызлары Мәдинә гаиләләре белән ике бала үстерә.

Таҗикстан Республикасының төньягында, Фирганә үзәнлегендә Исфара дип аталган шахтерлар шәһәре бар. Мәҗит әфәнде хәләл җефете Сайера ханым белән шунда туып-үскән.



Энесе Содир һәм оныгы Робия белән.

– Әти-әнием бик гади кешеләр иде, – дип сөйли ул. – Әтием башта шахтада эшләде, аннан автоколоннада ГАЗ-53 машинасын йөртте. Әни йорт тирәсендә кайнашты. Безнең балачак Советлар Союзы вакытына туры килде бит. Бик матур булып хәтердә калган. Телефоннар юк иде. Без хәтта телевизор да карамадык. Өйдәгеләр рөхсәт итмәде. Буш вакыт булуга, гел китап укыдык. Мин хәзер аңлыйм: бу күпкә файдалырак булгандыр. Чөнки фильмнарда сурәтләр карап утырасың. Ә китап укыганда фантазияңне эшкә җигәсең. Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты?» китабын укыгач, нинди хисләр кичергәнем әле дә исемдә. Бүгенге таҗик әдәбиятына нигез салучы классик Садриддин Айнинең бар булган әсәрләрен укып чыктым. Мәктәпне тәмамлагач, СССР Вузлар министрлыгы карары нигезендә Ленинград инженер-төзелеш институтына укырга кердем. Диплом алгач, Таҗикстанга кайтырга тиеш идем. Шулай итеп, Дүшәнбе шәһәрендәге Политехник институтында укыта башладым.

Оныклары Сафия белән Әнисә.

Гореф-гадәтләрне саклыйбыз

Килен-кияүләре барысы да таҗик милләтеннән икәнлеген белгәч, башта гаҗәпләнеп тә куйган идем. Казанда тормыш кордылар, ди бит. Ничек табып бетермәк кирәк? Шул хакта сорау биргәч, Мәҗит Насриевич: «Без бит гореф-гадәтләрне бик тә саклыйбыз. Туйларны Таҗикстанга кайтып уздырдык. Килен-кияүләрне дә шунда таптык. Элек-электән килгән гадәтләр дәвам итә әле бездә. Балаларның кемгә өйләнергә, кемгә кияүгә чыгарга тиешлеген әти-әниләр хәл итә. Ир балалар кайчагында үз фикерләрен әйтергә җөрьәт итсәләр дә, кызларга бу хокук бирелмәгән. Ата-аналар үзара сөйләшәләр, балаларга алар сүзеннән чыгарга ярамый. Ничек кенә булмасын, без аларга начарлык теләмибез бит инде.

– Ә мәхәббәт? – дигән сорау биргәч, Мәҗит Насриевич елмаеп кына куйды. Һәрхәлдә, аларның гаиләсендә аерылышулар булмаган. Димәк, әти-әниләр белеп сайлаганнар.

Мәҗит белән Сайераның үз язмышлары да шундый булган.

– Дөрес, без бер-беребезне белә идек. Бер мәктәптә укыдык. Ул миннән 7 яшькә кечерәк иде. Әнисе бик актив кеше, мәктәп директоры иде. Хәзер дә хәйрия эшләре белән шөгыльләнә әле.

Туебыз 8 март көнне булды. Бездә бит мондый зур бәйрәмнәр урамда уза, чөнки бик күп кунаклар килә. Монысы да – үзенә күрә элек-электән килгән гореф-гадәт. «Әйдә, кичереп торыйк», – дигән сүземә колак та салмадылар. Сайераның әнисе туйны мәктәпнең актлар залында оештырды. Әле дә хәтерлим: машина белән килеп туктадык, ике якта халык тезелгән, актлар залы да туп-тулы. Традициягә бик үк туры килеп бетмәде, әмма чып-чын комсомол туе кебек булды ул. Дүшәнбедән дусларым, хезмәттәшләрем дә кайткан иде.

Фән кешесе

Убойдуллаевларда гаиләнең иң зур казанышы дип хуҗа кешенең докторлык диссертациясен саныйлар. Ул аны 2022 елның февраль аенда яклаган һәм бу эшне гаиләнең уртак хезмәт җимеше дип саный. Эшләргә шартлар тудырып, йорт мәшәкатьләрен дә, балалар үстерүне дә үз өстенә алган хәләленә аеруча рәхмәтле ул.



Докторлык диссертациясен яклаганда.

Дүрт бала белән тулай торакның ике бүлмәсендә яшәгәндә, хуҗа кеше берсендә фәнни эш белән шөгыльләнгән, ә икенчесендә Сайера ханым дүрт бала белән тормыш алып барган. Фән кешесенең хезмәт хакы әллә ни түгел. Шуңа күрә аңа, базарга чыгып, эшмәкәрлек белән дә шөгыльләнергә туры килгән. Балалары әле дә: «Әти өстәл янында утырганда безне ишетми дә иде. Без балачакта бу хәлдән җайлы гына файдаландык. Берәр нәрсә сорыйбыз да, ул, уйламый-нитми генә, ярар, дип җавап бирә. Соңыннан исә, ник болай эшләдегез, дип аптырый иде», – дип искә төшерәләр. Гаиләсе тарафыннан үзенә булган мондый мөнәсәбәтне дә ул Көнчыгыш халыкларының традицияләренә бәйли.

Фән өлкәсенә юллар урау була. 1986 елда Мәҗит, сәламәтлеге какшау сәбәпле, Дүшәнбедән Исфарага кайтып китә. Башкарма комитетта эшли. Әмма күңеленә тынычлык таба алмый. Фән белән шөгыльләнәсе килә аның. Ленинградта үз белгечлеге буенча аспирантура ачылачагын ишеткәч, шунда юл ала. Әмма квоталар җирле халык өчен генә була. Тукталып калмый.

Йөри торгач, теләгенә ирешә. Өч ел эчендә кандидатлык диссертациясен яклый. Темасы да үзе өчен бик кызыклы була: «Төзелеш конструкцияләрен көчәйтү». Кире Дүшәнбегә кайтып, баш-аягы белән фән эшенә чумарга дигән теләк кенә барып чыкмый. Гражданнар сугышы комачаулый.

Бердәнбер көнне алар, атышларга түзә алмыйча, иң кирәкле әйберләрен генә җыеп, Исфарага юл тоталар. Шулай итеп, фән белән шөгыльләнергә бөтенләй мөмкинлек калмый. Ничек булса да, Россиягә китәргә кирәк, дигән уй шунда килә. Башта Уфага китеп, Башкортстан дәүләт университетында укыта башлый. Әмма бу да фәнни-тикшеренү эшләре булмый әле. Нәкъ шул вакытта туганнары Казанга күченә, Сайераның да алар янына китәсе килә.

– Казанга килгәч, иң беренче эш итеп инженер-төзелеш институтының металл конструкцияләр кафедрасына юл тоттым. Ул вакытта аның җитәкчесе профессор Иван Кузнецов иде. Документларымны күрсәттем, – дип искә ала Мәҗит. – «Бездә урын юк шул. Башка кафедраларга барып карыйк әле. Бәлки табылыр», – дип, мине Казан вузлары буенча җитәкләп диярлек йөртте. Шулай итеп, бер айдан Казан технологик фәнни-тикшеренү институтында урын барлыгы ачыкланды. Шунда мин кафедра мөдире Мурат Сираҗетдинов белән таныштым. Без фән өлкәсендә аның белән фикердәшләр булып чыктык. Бик күп эшләр эшләнде.

Оныклары Одил һәм Робия белән.

Сагыну

Бүген Мәҗит Насриевичның барлык туганнары да (алар биш бала үскәннәр) Россиядә, күбесе – Казанда. Аралашып яшиләр.

– Хәтта минем әтием дә монда җирләнгән, – ди ул. – Ул ел саен 2–3 ай кунак булып китә иде. Берсендә бик каты авырып китте. Саклап кала алмадык...

Казан – бик якын, безне сыендырган шәһәр. Әмма ничек кенә булмасын, туган җир сагындыра, әлбәттә. Ел саен бер тапкыр булса да кайтып килергә җай табабыз. Бабаларыбыз каны тамган тарихи җирләребезне оныклар да белеп, күреп калсын дип тырышабыз. Анда туганнарыбыз яши әле. Димәк, туган туфракның табигатенә хозурланып, татлы суларын эчеп, саф һавасын сулап кайтырга мөмкинлек тә бар дигән сүз. Гүзәл булса да торган җир, сагындыра туган ил, дип юкка гына әйтмиләр бит инде.

Бәйрәм

Сада

Таҗиклар гыйнвар ахырында Сада яки Иди Сада дип аталган зур бәйрәм үткәрәләр. Ул борынгы заманнардан килгән. Дөрес, бу бәйрәм билгеле бер вакыт онытылып торган. Әмма ул хәзер бик популяр.

Бәйрәм беренче чиратта утка бәйле. Шулай ук аны Кояшны олылауга бәйлиләр. Шуңа күрә дә бу көнне учак ягалар. Ут никадәр көчлерәк булса һәм югарырак үрмәләсә, ул елны уңыш шулкадәр мулрак була дигән ырым да бар. Бәйрәмнең исеме «сад» сүзеннән алынган. Ул фарсы һәм таҗик телендә «йөз» дигәнне аңлата. Бу сан җәйдән соң Нәүрүзгә кадәр ничә көн калганын белдерә.

Сада Кышны озату бәйрәменә дә охшаган. Борынгы заманда нәкъ шул көнне салкыннар белән хушлашып, язны каршылаганнар. Учак ягып, һаваны җылыта алуларына шатланганнар. Ул шулай ук җир эшләренә бәйле. Бүген Таҗикстанда бу көнне гадәттә ярминкәләр уздыралар. Шушы көннән башлап, игенчеләр орлыклар һәм җир эшкәртү өчен җиһазлар, җирнең үзен чәчүгә әзерли башлыйлар.

Далда

Сада бәйрәменең иң төп сые – далда. Аны өч сәгать буена төелгән бодайдан, бәрәннең баш-аякларыннан, фасольдән әзерлиләр.

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде
Фотолар – гаилә архивыннан

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 361

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+